**4 нче кисәк (2 нче тема)** ***(телефоннан сөйләшү)***
**Акбай:** Алло.
**Мияу:** Алло. Син кем?
**Акбай:** Мин Акбай.
**Мияу:** Исәнме, Акбай.
**Акбай:** Хәерле көн, Мияу. Хәлләр ничек?
**Мияу:** Әйбәт. Рәхмәт. Акбай, хәлләр ничек?
**Акбай:** Әйбәт. Рәхмәт. Сау бул, Мияу.
**Мияу:** Сау бул, Акбай.

**5 нче кисәк (2 нче тема).**
**Җыр. "Хәерле көн".**
Хәерле көн, әти *(ир-ат тавышы).*
Хәерле көн, әни *(хатын-кыз тавышы).*
Хәерле көн, бабай *(ир-ат тавышы).*
Хәерле көн, әби *(хатын-кыз тавышы).*

**Тема: "Син кем?"**
**6 нчы кисәк (4 нче тема).**

**- Акбай и Мияу тоже хотят играть с нами в сказку «Репка». Они должны хорошо запомнить ваши имена. Давайте, проверим. Акбай отвернётся, а вы по очереди будете подходить, и здороваться с ним. Акбай будет угадывать, кто это** *(ир-ат тавышы).*
**Мияу:** Исәнме, Акбай.
**Акбай:** Син кем? Оля?
**Мияу:** Юк, мин Мияу.

**Тема: "Шалкан" экиятен сәхнәләштерү.**
**7 нче кисәк (5 нче тема).**
**Акбай:** Бу кем?
**Мияу:** Бу әти.
**Акбай:** Әйе, әти. Бу кем?
**Мияу:** Бу әни.
**Акбай:** Юк. Бу кем?
**Мияу:** Бу кыз.
**Акбай:** Юк. Бу кем?
**Мияу:** Бу бабай.
**Акбай:** Әйе, бу бабай.

**8 нче кисәк (5 нче тема).**

**- Ребята, слушайте. Спросите: Это кто?-Бу кем?** *(ир-ат тавышы)*
- Исәнмесез *(әни тавышы, озын пауза-10 секунд)*
- *(балалар сорый) ... Бу кем?*
- Бу әни *(әни тавышы, кыска пауза-3 секунд).*
- Исәнмесез *(әти тавышы, озын пауза-6 секунд)*
- *(балалар сорый) ... Бу кем?*
- Бу әти *(әти тавышы, кыска пауза-3 секунд).*
- Хәерле көн, мыр-р-р...*(песи тавышы, озын пауза-6 секунд)*
- *(балалар сорый) ... Бу кем?*
- Бу песи *(песи тавышы)*
- Хәлләр ничек? Р-р-р...*(эт тавышы, озын пауза-6 секунд)*
- *(балалар сорый) ... Бу кем?*
- Бу эт *(эт тавышы, кыска пауза-3 секунд)*
- Чи, чи чи. Исәнмесез *(тычкан тавышы, озын пауза-6 секунд)*
- *(балалар сорый) ... Бу кем?*
- Бу тычкан *(тычкан тавышы).*

**Тема: "Бу нәрсә?"**
**9 нчы кисәк (7 нче тема).**
**- Ребята, мы с вами хорошо потрудились, вырастили большую репку. Молодцы. Теперь можно поиграть. Акбай и Мияу принесли нам игрушки. Давайте, спросим: Это что? – Бу нәрсә?** *(ир-ат тавышы).*
**Акбай:** Бу нәрсә?
**Мияу:** Бу тычкан.
**Акбай:** Нинди тычкан?
**Мияу:** Кечкенә тычкан.

**10 нчы кисәк (7 нче тема).**
***Акбай белән Мияу сатучы-сатып алучы рольләрендә.***
**Акбай:** Исәнме, Мияу.
**Мияу:** Исәнме, Акбай.
**Акбай:** Нәрсә кирәк?
**Мияу:** Туп кирәк.
**Акбай:** Нинди туп?
**Мияу:** Зур, матур туп.
**Акбай:** Мә, зур, матур туп.
**Мияу:** Рәхмәт. Саубул Акбай.
**Акбай:** Саубул, Мияу.

**Тема: "Кем нишли?"**
**11 нче кисәк (8 нче тема).**
**- Ребята, слушайте вопрос, найдите соответствующую картинку и ответьте** *(ир-ат тавышы).*
- Әти нишли? *(ир-ат тавышы, озын пауза -20 секунд, балалар рәсемне таба, җавап бирәләр: әти йоклый).*

- Әйе, эти йоклый *(хатын-кыз тавышы).*
- Әни нишли? *(ир-ат тавышы, озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, җавап бирәләр: әни юа).*
- Әйе, әни юа *(хатын-кыз тавышы).*
- Кыз нишли? *(ир-ат тавышы, озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, җавап бирәләр: кыз утыра).*
- Әйе, кыз утыра *(хатын-кыз тавышы).*
- Малай нишли? *(ир-ат тавышы, озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, җавап бирәләр: малай йоклый).*
- Әйе, малай йоклый *(хатын-кыз тавышы).*
- Әби нишли? *(ир-ат тавышы, озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, җавап бирәләр: әби юа).*
- Әйе, әби юа *(хатын-кыз тавышы).*
- Бабай нишли? *(ир-ат тавышы, озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, җавап бирәләр: бабай утыра).*
- Әйе, бабай утыра *(хатын-кыз тавышы).*

**Тема: "Дусларны сыйлыйбыз".**
**12 нче кисәк (10 нчы тема).**
**Җыр. "Нишли?"**
Нишли? Нишли?
Йоклый, йоклый.
Нишли? Нишли?
Утыра, утыра.
Нишли? Нишли?
Ашый, ашый.
Нишли? Нишли?
Эчә, эчә.

**Тема: "Нишлисең?"**
**13 нче кисәк (11 нче тема).**
**Ребята, Акбай и Мияу угощаются. Мияу спрашивает: Акбай, что делаешь? – Нишлисең?** *(ир-ат тавышы)*
**Мияу:** Акбай, нишлисең?
**Акбай:** Кушаю. Ашыйм, ашыйм. Мияу, нишлисең?
**Мияу:** Пью. Эчәм, эчәм *(озын пауза)*
***Тәрбияче:*** *Спросите, что делает Акбай?*
***Бергә:*** *Акбай, нишлисең?*
**Акбай:** Ашыйм *(озын пауза).*
***Тәрбияче:*** *Спросите, что делает Мияу?*
***Бергә:*** *Мияу, нишлисең?*
**Мияу:** Эчәм.

**Тема: "Нишлисең?"** ***(телефоннан сөйләшү)***
**14 нче кисәк (11 нче тема).**

- Исәнме, хәерле көн, Оля *(малай тавышы).*
- Исәнме, хәерле көн. Син кем? *(кыз тавышы).*
- Мин Коля *(малай тавышы).*
- Хәлләр ничек, Коля? *(кыз тавышы).*
- Әйбәт. Хәлләр ничек, Оля? *(малай тавышы).*
- Әйбәт *(кыз тавышы).*
- Оля, нишлисең? *(малай тавышы).*
- Алма ашыйм. Коля, нишлисең? *(кыз тавышы).*
- Чәй эчәм *(малай тавышы).*
- Сау бул, Коля *(кыз тавышы).*
- Сау бул, Оля *(малай тавышы).*

**Тема: “Әйдәгез, уйныйбыз”.**
**15 нче кисәк (13 нче тема).**
- Исәнме, Оля *(малай тавышы).*
- Исәнме, Коля *(кыз тавышы).*
- Хәерле көн *(малай тавышы).*
- Хәерле көн *(кыз тавышы).*
- Хәлләр ничек? *(малай тавышы).*
- Әйбәт. Коля, хәлләр ничек? *(кыз тавышы).*
- Әйбәт *(малай тавышы).*
- Коля, нишлисең? *(кыз тавышы).*
- Ботка ашыйм. Син нишлисең? *(малай тавышы).*
- Мин уйныйм *(кыз тавышы).*
- Сау бул, Оля *(малай тавышы).*
- Сау бул, Коля *(кыз тавышы).*

**Тема: “Кунак килде”.**
**16 нчы кисәк (14 нче тема).**
**Ишек шакыган тавыш** *(озын пауза-10 секунд).*
***Бергә:*** *Кем анда?*
**Әби:** Мин әби *(кыска пауза-4 секунд).*
***Бергә:*** *Әби, кил монда.*
**Ишек ачылган тавыш** *(кыска пауза-3 секунд).*
**Әби:** Исәнмесез, балалар *(озын пауза-10 секунд).*
***Бергә:*** *Исәнме, әби. Әби, хәлләр ничек?*
**Әби:** Әйбәт, рәхмәт*(кыска пауза-4 секунд).*
- **Предложите бабушке сесть на стул** *(хатын-кыз тавышы, кыска пауза-4 секунд).*
***Бергә:*** *Әби, утыр.*
- **Әби нишлисең?** *(хатын-кыз тавышы).*
**Әби:** Сижу - утырам. Утырам.

**17 нче кисәк (14 нче тема).**

**- Бабушка ты сидишь на стуле, как скажешь, что сидишь** *(хатын-кыз тавышы).*
**Әби:** Утырам.
**- Мияу, ты сидишь на стуле, как скажешь, что сидишь** *(хатын-кыз тавышы).*
**Мияу:** Утырам.
**- Акбай, ты сидишь на стуле, как скажешь, что сидишь** *(хатын-кыз тавышы).*
**Акбай:** Утырам.

**18 нче кисәк (14 нче тема).**
**Мияу:** Әби, кил монда, утыр.
**Әби:** Рәхмәт.
**Мияу:** Әби, нишлисең?
**Әби:** Утырам.
**Мияу:** Әби, мә чәй, эч.
**Әби:** Рәхмәт, чәй тәмле.

**Тема: "Кафега барабыз".**
**19 нчы кисәк (16 нчы тема).**
**- Акбай и Мияу встретились по пути в кафе. Слушайте, как они разговаривали друг с другом** *(хатын-кыз тавышы).*
**Акбай:** Исәнме, Мияу.
**Мияу:** Исәнме, Акбай. Хәлләр ничек?
**Акбай:** Әйбәт. Хәлләр ничек?
**Мияу:** Әйбәт.
**Акбай:** Мияу, куда идешь? Кая барасың?
**Мияу:** Иду в кафе. Кафега барам. Акбай, кая барасың?
**Акбай:** Кафега барам.
**Тема: "Без кафеда"** ***(телефоннан сөйләшү)***
**20 нче кисәк (17 нче тема).**
**- Слушайте, как Коля угощается в кафе. Из кафе звонит Оле.** *(ир-ат тавышы).*
- Исәнме, Оля *(малай тавышы).*
- Исәнме, Коля *(кыз тавышы).*
- Хәлләр ничек? *(малай тавышы).*
- Әйбәт. Коля, син нишлисең? *(кыз тавышы).*
- Мин бәрәңге ашыйм *(малай тавышы).*
- Бәрәңге тәмлеме? *(кыз тавышы).*
- Әйе, бәрәңге тәмле. Оля, син нишлисең? *(малай тавышы).*
- Мин уйныйм *(кыз тавышы).*
- Сау бул, Оля *(малай тавышы).*
- Сау бул, Коля *(кыз тавышы).*

**Тема: "Күңелле уеннар".**

**21 нче кисәк (20 нче тема).**
**- У меня тоже есть рисунки, давайте их посмотрим (** *клоун,ир-ат тавышы).*
- Зайчик прыгает. Куян сикерә. Сикерә *(озын пауза-20 секунд).*
- Зайчик бежит. Куян йөгерә. Йөгерә.

**22 нче кисәк (20 нче тема).**
**- Слушай. Найди соответствующий рисунок** *(ир-ат тавышы)*
-Бу төлке. Төлке зур, матур. Төлке утыра *(озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, күрсәтә).*
-Бу керпе. Керпе кечкенә, матур. Керпе уйный *(озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, күрсәтә).*
-Бу аю. Аю зур, матур. Аю йоклый *(озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, күрсәтә).*
-Бу песи. Песи кечкенә, матур. Песи сөт эчә *(озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, күрсәтә).*
-Бу эт. Эт зур, матур. Эт ашый *(озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, күрсәтә).*
-Бу кыз. Кыз кечкенә, матур. Кыз кул юа *(озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, күрсәтә).*
-Бу куян. Куян кечкенә, матур. Куян сикерә *(озын пауза-20 секунд, балалар рәсемне таба, күрсәтә).*
-Бу төлке. Төлке зур, матур. Төлке йөгерә *( балалар рәсемне таба, күрсәтә).*

**23 нче кисәк (20 нче тема).**
***Җырлы-биюле уен "Әйдәгез, биибез".***
1) Бар монда зур төлке.
Зур төлке, матур төлке.
**Төлке, төлке кил әле,**
**Биеп-биеп кит әле (2 тапкыр).**
2)Бар монда зур аю,
Зур аю, матур аю.
**Аю, аю кил әле,**
**Биеп-биеп кит әле (2 тапкыр).**
3)Бар кечкенә куян,
Кечкенә, матур куян.
**Куян, куян кил әле,**
**Биеп-биеп кит әле (2 тапкыр).**
4)Бар кечкенә керпе,
Кечкенә, матур керпе.
**Керпе, керпе кил әле,**
**Биеп-биеп кит әле (2 тапкыр).**

**Тема: "Спорт бәйрәменә әзерләнәбез".**

**24 нче кисәк (22 нче тема).**
**- Акбай и Мияу готовятся на спортивный праздник. Мияу, кая барасың?** *(ир-ат тавышы)*
**Мияу:** Спорт бәйрәменә барам.
**- Акбай, кая барасың?** *(ир-ат тавышы).*
**Акбай:** Спорт бәйрәменә барам.
**Мияу:** Акбай, сикер! Акбай, син нишлисең?
**Акбай:** Мин сикерәм. Мияу, беги! Мияу, йөгер! Мияу, йөгер! Мияу, син нишлисең?
**Мияу:** Я бегу. Мин йөгерәм. Йөгерәм.

**Тема: "Бәйрәмгә барабыз".**
**25 нче кисәк (23 нче тема).**
**- Акбай и Мияу собрались в Казань. Покупают в кассе билет** *(хатын-кыз тавышы)*
**Мияу:** Акбай, билет бир әле.
**Акбай:** Кая барасың?
**Мияу:** Казанга барам.
**Акбай:** Мә, билет.
**Мияу:** Рәхмәт.
**- Мы с вами тоже поедем в город Казань. Спросите, у кассира билет** *(хатын-кыз тавышы)*

**26 нчы кисәк (23 нче тема).**
**- Мы проезжаем заповедную зону. Тут обитают дикие животные, которые охраняются** *(кыска пауза, ир-ат тавышы)*
**- Ребята, скажите, кого вы видите? Что они делают?** *(ир-ат тавышы)*

**27 нче кисәк (23 нче тема).**
**- Остановка для отдыха. Здесь можно поесть и попить** *(кыска пауза, ир-ат тавышы)*
**Акбай:** Мин өчпочмак ашыйм. Син нишлисең?
**Мияу:** Мин чәк-чәк ашыйм.

**28 нче кисәк (23 нче тема).**
***Җыр.***
Мин барам, барам, барам,
Казанга барам, барам.
Әйе шул, әйе шул,
Казанга барам, барам.

**Тема: "Казанда спорт бәйрәме".**
**29 нчы кисәк (25 нче тема).**
**- Исәнме, мин корреспондент. Син кем?** *(хатын-кыз тавышы).*
**Акбай:** Исәнмесез. Мин Акбай.

**- Сиңа ничә яшь?** *(хатын-кыз тавышы).*
**Акбай:** 6 яшь.
**- Син нишлисең?** *(хатын-кыз тавышы).*
**Акбай:** Мин сикерәм.
**- Рәхмәт** *(хатын-кыз тавышы).*
**- Исәнме, мин корреспондент. Син кем?** *(хатын-кыз тавышы).*
**Мияу:** Исәнмесез. Мин Мияу.
**- Сиңа ничә яшь?** *(хатын-кыз тавышы).*
**Мияу:** 6 яшь.
**- Син нишлисең?** *(хатын-кыз тавышы).*
**Мияу:** Мин йөгерәм.
**- Рәхмәт** *(хатын-кыз тавышы).*

**30 нчы кисәк (25 нче тема).**
*(Физминутка үткәрер өчен дәртле музыкага җырланса, яхшы булыр иде)*
Әй, нәниләр, нәниләр
Ардык без, дип әйтмиләр.
Аякларын күтәреп,
Матур итеп атлыйлар.
Хәзер барабыз алга
Егылмыйча, син атла.
1,2,3,4,5.
Хәзер барабыз артка
Егылмыйча, син атла.
6,7,8,9,10.
Егылмыйча, син атла.
1,2,3,4,5.
Хәзер барабыз артка
Егылмыйча, син атла.
6,7,8,9,10.

**Тема: "Безнең дуслар".**
**31 нче кисәк (28 нче тема).**
**- Ребята, к нам из цирка пришли домашние птицы. Давайте, с ними познакомимся** *(хатын-кыз тавышы, кыска пауза).*
**Әтәч тавышы:** Кикрикүк. Әтәч. Әтәч. Әтәч *(озын пауза-6секунд).*
***Бергә:*** *Әтәч. Әтәч. Әтәч.*
**Тавык тавышы:** Ко-ко-ко. Тавык. Тавык. Тавык *(озын пауза -6 секунд).*
***Бергә:*** *Тавык. Тавык. Тавык.*

**32 нче кисәк (28 нче тема).**
***Җыр.***
1)Бар монда зур әтәч,
Зур әтәч, матур әтәч.
**Әтәч, әтәч кил әле,**

**Биеп, биеп кит әле (2 тапкыр).**
2)Бар кечкенә тавык,
Кечкенә, матур тавык.
**Тавык, тавык кил әле,**
**Биеп, биеп кит әле (2 тапкыр).**

**Тема: “Үрдәк дусларын тапты”.**
**33 нче кисәк (29 нчы тема).**
**Ишек шакыган тавыш** *(кыска пауза-6 секунд).*
***Бергә:*** *Кем анда?*
**Үрдәк:** Бак-бак, мин *(кыска пауза-6 секунд).*
***Бергә:*** *Кил монда.*
**Ишек ачылган тавыш** *(кыска пауза-3 секунд).*
**Үрдәк:** Исәнмесез *(кыска пауза-6 секунд).*
***Бергә:*** *Исәнмесез. Син кем?*
**Үрдәк:** Мин үрдәк. Мин үрдәк. Үрдәк.

**34 нче кисәк (29 нчы тема).**
**Үрдәк:** Бак-бак. Хозяин цирка ищет своих зверей, птиц. Отправил меня за ними.
**- Утка долго шла проголодалась, давайте, угостим. Үрдәк, кил монда, утыр. Мә, ботка аша** *(хатын-кыз тавышы).*
**Үрдәк:** Бак-бак. Рәхмәт, ботка тәмле.
**- Давайте, позовем зверей, птиц и угостим их тоже** *(хатын-кыз тавышы).*

**Тема: “Акбай чана шуа”.**
**35 нче кисәк (31 нче тема).**
**-Слушайте, как будет санки по-татарски** *(ир-ат тавышы, кыска пауза-3 секунд).*
**-Бу чана** *(ир-ат тавышы, пауза-3 секунд, тәрбияче куянның чанасын күрсәтә)*
**-Бу чана** *(кыска пауза-3 секунд).* **Повторите** *(кыска пауза-3 секунд).* **Бу чана** *(ир-ат тавышы, пауза- 6 секунд, балалар кабатлый)*
**-Бу чана** *(ир-ат тавышы, пауза- 6 секунд, балалар кабатлый)*
**-Слушайте** *(кыска пауза-3 секунд).* **Заяц катается на санках** *(ир-ат тавышы, кыска пауза-3 секунд)*
**-Куян чана шуа** *(кыска пауза-3 секунд).* **Куян чана шуа** *(ир-ат тавышы).*

**36 нчы кисәк (31 нче тема).**
-Куян нишли? *(ир-ат тавышы).*
-Чана шуа *(хатын-кыз тавышы).*
-Төлке нишли? *(ир-ат тавышы).*
-Чана шуа *(хатын-кыз тавышы).*
-Бүре нишли? *(ир-ат тавышы).*

-Чана шуа *(хатын-кыз тавышы).*
-Аю нишли? *(ир-ат тавышы).*
-Чана шуа *(хатын-кыз тавышы).*

**Тема: “Чана шуам”.**
**37 нче кисәк (32 нче тема).**
***Акбай белән Мияу җырлыйлар.***
Мин Акбай, мин Акбай,
Зур Акбай, матур Акбай *(Акбай тавышы).*
Мин Мияу, мин Мияу,
Зур Мияу, матур Мияу *(Мияу тавышы).*

**38 нче кисәк (32 нче тема).**
**Мияу:** Акбай, бу нәрсә?
**Акбай:** Бу чана.
**Мияу:** Чана нинди?**.**
**Акбай**: Чана зур, кызыл.
**Чана шуган тавыш ишетелә** *(кыска пауза-3 секунд).*
**Мияу:** Акбай, нишлисең?
**Акбай:** Мин чана шуам. Мияу, кил монда. Утыр.
**Мияу:** Мин чана шуам.

**Тема: “Әйдә, бие”.**
**39 нчы кисәк (34 нче тема).**
**“Зиләйлүк” татар халык көе ишетелә** *(сүзләрне әйткәндә көй акрын гына ишетелә)*
**- Ребята, слушайте, какая красивая, весёлая плясовая мелодия «Зиләйлүк». Так и хочется поплясать. Давайте вместе попросим: Акбай, танцуй. Акбай, бие. Мияу, танцуй. Мияу, бие** *(хатын-кыз тавышы).*

**40 нчы кисәк (34 нче тема).**
**<u>“Зиләйлүк” татар халык көе.</u>**

**Тема: “Без биибез”.**
**41 нче кисәк (35 нче тема).**
**<u>Татар халык бию көе.</u>**

**Тема: “Мияуның бүлмәсен бизибез”.**
**42 нче кисәк (37 нче тема).**
**Акбай:** Скоро у Мияу день рождение. Я не приготовил ей подарок. А знаете почему? Зашёл в магазин, где продавались огромные воздушные шары. Но забыл, как назвать цвета по-татарски и стал показывать пальцами. Продавцы не захотели со мной разговаривать, с таким

невежливым. Чтобы такого не повторилось, помогите мне вспомнить цвета по-татарски.

**43 нче кисәк (37 нче тема)**
**Акбай *(җырлап әйтә)*:** Если нравится тебе, то делай так. Әгәр синә ошый икән, син бие *(озын пауза-10секунд, Акбай бии, балалар кушыла).*
**Акбай:** Мин биим *(кыска пауза-4 секунд).*
***Бергә: Мин биим.***
**Акбай *(җырлап әйтә)*:** Әгәр синә ошый икән, син сикер *( пауза-4 секунд).*
**Акбай:** Мин сикерәм *(кыска пауза-4 секунд)*
***Бергә: Мин сикерәм.***
**Акбай *(җырлап әйтә)*:** Әгәр синә ошый икән, син йөгер *( пауза-4 секунд).*
**Акбай:** Мин йөгерәм *(кыска пауза-4 секунд)*
***Бергә: Мин йөгерәм.***
**Акбай *(җырлап әйтә)*:** Әгәр синә ошый икән, син уйна *( пауза-4 секунд).*
**Акбай:** Мин уйныйм *(кыска пауза-4 секунд)*
***Бергә: Мин уйныйм.***
**Акбай *(җырлап әйтә)*:** Әгәр синә ошый икән, син утыр *( пауза-4 секунд).*
**Акбай:** Мин утырам *(кыска пауза-4 секунд)*
***Бергә: Мин утырам.***

**44 нче кисәк (37 нче тема).**
**Акбай:** Я думаю, что день рождение Мияу будет интересным, если мы для неё выучим песню.
***Җыр "Туган көн".***
Мияуның туган көненә
Без пешердек ак ипи.
Менә шундый ипи зур,
Менә шундый кечкенә.
Менә шундый тәмле,
Менә шундый баллы.
Әйе шул, әйе шул,
Әйе шул, ипи тәмле.

**Тема: "Туган көнгә бүләк әзерлибез".**
**45 нче кисәк (38 нче тема).**
**Акбай:** На день рождение Мияу я приготовил в подарок песню.
***Бергә:*** *Акбай, җырла.*
**Акбай:** Я люблю петь! Я пою – мин җырлыйм. Мин җырлыйм, җырлыйм (*җырлый:* лә-лә-лә).
***Бергә:*** *Акбай, син нишлисең?*
**Акбай:** Мин җырлыйм. А вы любите петь?

**46 нчы кисәк (38 нче тема).**

***Җыр.***
1)Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
2) Мин биим, биим, биим.
Мин матур биим, биим.
Мин биим, биим, биим,
Мин матур биим, биим.
Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,
Мин матур биим, биим.

**Тема: “Мияуның туган көне”.**
**47 нче кисәк (40 нчы тема).**

***Җыр “Туган көн”.***
Мияуның туган көненә
Без пешердек ак ипи.
Менә шундый ипи зур,
Менә шундый кечкенә.
Менә шундый тәмле,
Менә шундый баллы.
Әйе шул, әйе шул,
Әйе шул, ипи тәмле.

**Мияу:** Зур рәхмәт.
**Акбай:** Ребята, видите, Мияу не просто говорит спасибо, а “большое спасибо” – “зур рәхмәт”.
**Мияу:** Зур рәхмәт.
**Акбай:** Попросите Мияу, чтобы она станцевала *(кыска пауза-4 секунд).*
***Бергә:*** *Мияу, әйдә, бие (пауза-6 секунд).*
**Мияу татар бию көенә бии** *(кыска пауза-4 секунд).*
***Бергә:*** *Мияу матур бии.*
**Мияу:** Зур рәхмәт.

**Тема: “Туган көн табынында”.**
**48 нче кисәк (41 нче тема).**
**- День рождения продолжается** *(хатын-кыз тавышы).*
**Мияу:** Я вам тоже приготовила сюрприз. Отгадайте мои загадки.
1)Мин зур, матур, әйбәт. Мин йөгерәм, сикерәм, утырам, җырлыйм: “Тяф-тяф”. Бел *(ир-ат тавышы, озын пауза).*
- Төлке *(хатын-кыз тавышы).*

2)Мин кара. Мин кечкенә, матур, әйбәт. Мин йөгерәм, сикерәм, биим, ашыйм, җырлыйм: “Чи-чи-чи”. Бел *(ир-ат тавышы, озын пауза).*
- Тычкан. *(хатын-кыз тавышы).*
3)Мин кызыл. Мин зур, матур, әйбәт. Мин ипи ашыйм, су эчәм, биим, җырлыйм: “Кикрикүк”. Бел. *(ир-ат тавышы, озын пауза).*
- Әтәч *(хатын-кыз тавышы).*
4)Мин ак. Мин кечкенә, матур, әйбәт. Мин ипи ашыйм, йөгерәм, җырлыйм: “Ко-ко-ко”. Бел. *(ир-ат тавышы, озын пауза).*
- Тавык *(хатын-кыз тавышы).*

**49 нчы кисәк (41 нче тема).**
**Мияу:** Әйдәгез, балалар, утырыгыз. Вы сидите за волшебным праздничным столом, будьте вежливы, угощайте друг-друга.
**Мияу:** Нәрсә кирәк?
**Акбай:** Алма кирәк.
**Мияу:** Нинди алма?
**Акбай:** Яшел, зур, тәмле алма.
**Мияу:** Мә, яшел, зур, тәмле алма.
**Акбай:** Зур рәхмәт.
**Мияу:** Акбай, син нишлисең?
**Акбай:** Мин алма ашыйм.
**Мияу:** Алма тәмлеме?
**Акбай:** Әйе, алма тәмле. Мин алма яратам.

**Тема: “Күңелле сәяхәт”.**
**50 нче кисәк (43 нче тема).**
- Малай китап укый *(пауза-3 секунд)*. Малай китап укый *(ир-ат тавышы, тәрбияче рәсемен күрсәтә, пауза -4 секунд).*
- Кыз китап укый *(пауза-3 секунд)*. Кыз китап укый *(хатын-кыз тавышы, тәрбияче рәсемен күрсәтә, пауза -4 секунд).*
- Куян китап укый *(пауза-3 секунд)*. Куян китап укый *(ир-ат тавышы, тәрбияче рәсемен күрсәтә, пауза -4 секунд).*
- Төлке китап укый *(пауза-3 секунд)*. Төлке китап укый *(хатын-кыз тавышы, тәрбияче рәсемен күрсәтә).*

**Тема: “Күңелле сәяхәт”.**
**51 нче кисәк (44 нче тема).**
**Мияу:** Перед нами лес. Ребята, смотрите, лесной компьютер, а в компьютере электронное письмо. Это письмо от волшебника. В нем написано, что волшебник рисует –рәсем ясый. Послушайте и повторите за ним. Если мы выполним задание лесного волшебника сможем идти дальше.
- Рәсем ясыйм. Алма ясыйм *(кыска пауза- 3секунд).* Алма ясыйм *(озын пауза-6 секунд, ир-ат тавышы, тәрбияче рәсемне күрсәтеп кабатлый) – Рәсем ясыйм. Алма ясыйм.*

- Рәсем ясыйм. Туп ясыйм *(кыска пауза- 3секунд).* Туп ясыйм *(озын пауза-6 секунд, ир-ат тавышы, тәрбияче рәсемне күрсәтеп кабатлый) – Рәсем ясыйм. Туп ясыйм.*
- Рәсем ясыйм. Шар ясыйм *(кыска пауза- 3секунд).* Шар ясыйм *(озын пауза-6 секунд, ир-ат тавышы, тәрбияче рәсемне күрсәтеп кабатлый) – Рәсем ясыйм. Шар ясыйм.*
- Рәсем ясыйм. Китап ясыйм *(кыска пауза- 3секунд).* Китап ясыйм *(озын пауза-6 секунд, ир-ат тавышы, тәрбияче рәсемне күрсәтеп кабатлый) – Рәсем ясыйм. Китап ясыйм.*

**52 нче кисәк (44 нче тема).**
**Мияу:** Ребята, я тоже люблю рисовать. Я рисую яблоко – мин алма ясыйм.
- Мин рәсем ясыйм. Мин алма ясыйм *(ир-ат тавышы, озын пауза-10 секунд, балалар рәсемне (һавада) “ясыйлар”, җөмләне кабатлыйлар) – Мин рәсем ясыйм. Мин алма ясыйм.*
- Мин рәсем ясыйм. Мин туп ясыйм *(ир-ат тавышы, озын пауза-10 секунд, балалар рәсемне (һавада) “ясыйлар”, җөмләне кабатлыйлар) – Мин рәсем ясыйм. Мин туп ясыйм.*
- Мин рәсем ясыйм. Мин шар ясыйм *(ир-ат тавышы, озын пауза-10 секунд, балалар рәсемне (һавада) “ясыйлар”, җөмләне кабатлыйлар) – Мин рәсем ясыйм. Мин шар ясыйм.*
- Мин рәсем ясыйм *(ир-ат тавышы) – Мин рәсем ясыйм.*

**53 нче кисәк (44 нче тема) *(телефоннан сөйләшү).***
**Мияу(шалтырата):** .... (пауза) *Хәерле көн.*
**Тылсымчы:** Исәнмесез.
**Мияу:** ... (пауза) *Хәлләр ничек?*
**Тылсымчы:** Әйбәт. Син нишлисең?
**Мияу:** .... (пауза) *Мин рәсем ясыйм.*
**Тылсымчы:** Нинди рәсем?
**Мияу:** ... (пауза) *Алма, туп, шар, китап.*
**Тылсымчы:** Әйбәт, килегез мәктәпкә. Приходите в школу.
**Мияу:** ... (пауза) *Мәктәпкә?*
**Тылсымчы:** Әйе, мәктәпкә.
**Мияу:** ... (пауза) *Рәхмәт. Сау булыгыз.*
**Тылсымчы:** Сау булыгыз.

**54 нче кисәк (46 нчы тема).**
**Мияу:** Ребята, лесной волшебник приглашает нас в волшебную страну, где говорят только на татарском языке. Возьмите телефон, расскажите друг-другу, что вы поете, танцуете, рисуете, читаете.

**55 нче кисәк (46 нчы тема).**
**Мияу:** Молодцы ребята. Мы теперь точно попадем в волшебную страну “Школа”- “Мәктәп”.

**56 нчы кисәк (46 нчы тема).**
**Акбай:** Ребята, мы можем продолжить путь, ведь лесной волшебник пригласил нас в страну, которая называется “Школа” – “Мәктәп”. Путешествие продолжается. Но что это? На нашем пути высокая гора, чтобы пройти гору нужно прочитать пиктограммы. Если мы поймем, что написано, гора даст нам продолжить дорогу.
**Мияу** ***(пиктограмма күрсәтеп):*** Кем укый?
**Акбай:** Мин укыйм.
**Акбай** ***укый:*** Малай рәсем ясый.
**Мияу** ***(пиктограмма күрсәтеп):*** Кем укый?

**57 нче кисәк (46 нчы тема).**
**Мияу:** Трудное было задание, но мы справились. Дорога свободна. Нас ждут удивительные приключения в следующий раз.

**58 нче кисәк (47 нче тема).**
***Җыр.***
1)Мин барам, барам, барам,
Мәктәпкә барам, барам.
Китап, карандаш алам,
Мәктәпкә барам, барам.
2)Мин барам, барам, барам,
Мәктәпкә барам, барам.
Китап укыйм, рәсем ясыйм,
4-ле, 5-леләр алам.

**59 нчы кисәк (47 нче тема).**
**Мияу:** Ребята, вот мы с вами дошли в волшебную страну “Школа” – “Мәктәп”. В школу зайдет тот, кто скажет, что нарисовано на пригласительных билетах.

**60 нчы кисәк (47 нче тема).**
**Акбай:** Исәнмесез, балалар *(кыска пауза-4 секунд)*
***Бергә:*** *Исәнме, Акбай.*
**Акбай:** Хәлләр ничек? *(кыска пауза-4 секунд)*
***Бергә:*** *Әйбәт.*
**Акбай:** Вы очень быстро прошли препятствия. Я вас поздравляю, возьмите подарки.
**Тема: “Мәктәптә”.**
**61 нче кисәк (49 нчы тема).**
**Мияу:** Нәрсә кирәк?
**Акбай:** Аш кирәк.
**Мияу:** Мә аш, аша.
**Акбай:** Рәхмәт.

**Мияу:** Акбай, нишлисең?
**Акбай:** Мин аш ашыйм.
**Мияу:** Аш нинди?
**Акбай:** Аш тәмле. Бик тәмле. Мин аш яратам.

**Тема: “Уку бүлмәсе”.**
**62 нче кисәк (50 нче тема).**
**Акбай:** Ребята, продолжим путешествие по волшебной стране “Мәктәп”.

**63 нче кисәк (50 нче тема).**
**Акбай:** Бу нәрсә?
**Мияу:** Белмим.
**Акбай:** Бу дәфтәр. Дәфтәр.
**Мияу:** Дәфтәр. Дәфтәр.
**Акбай:** Нинди дәфтәр?
**Мияу:** Чиста, матур, зур дәфтәр.
**Акбай:** Ничә дәфтәр?
**Мияу:** Бер дәфтәр.

**Тема: “Өстәл театры “Теремкәй” әкияте”.**
**64 нче кисәк (52 нче тема)**
- Сегодня я вам расскажу сказку “Теремок”.
Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә *(хатын-кыз тавышы)*
**Ишек шакыган тавыш.**
- Теремкәйдә кем яши? Юк, яшәми.
Теремкәйгә тычкан килә *(хатын-кыз тавышы)*
**Тычкан (ишек шакый):** Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши? *(кыска пауза).*
**Тычкан:** Юк, яшәми. Мин яшим.
-Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә.
Теремкәйдә тычкан яши
Теремкәйгә куян килә *(хатын-кыз тавышы)*
**Куян (ишек шакый):** Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан. Син кем?
**Куян:** Мин куян. Матур куян.
**Тычкан:** Әйдә, кил монда.
**Куян (керә):** Мин сикерәм. Әйдәгез, сикерәбез *(озын пауза, балалар сикерәләр).*
- Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә.
Теремкәйдә тычкан яши.
Теремкәйдә куян яши.
Теремкәйгә бүре килә *(хатын-кыз тавышы)*

**Бүре (ишек шакый):** Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан.
**Куян:** Мин куян.
**Тычкан, куян:** Син кем?
**Бүре:** Мин бүре. Мин зур, кара бүре.
**Тычкан, куян:** Әйдә, кил монда.
**Бүре (керә):** Мин йөгерәм. Әйдәгез, йөгерәбез *(озын пауза, балалар йөгерәләр).*
- Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә.
Теремкәйдә тычкан яши.
Теремкәйдә куян яши.
Теремкәйдә бүре яши.
Теремкәйгә төлке килә *(хатын-кыз тавышы)*
**Төлке (ишек шакый):** Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан.
**Куян:** Мин куян.
**Бүре:** Мин бүре.
**Тычкан, куян, бүре:** Син кем?
**Төлке:** Мин төлке. Мин зур, матур төлке.
**Тычкан, куян, бүре:** Әйдә, кил монда.
**Төлке (керә):** Мин биим. Әйдәгез, биибез *(озын пауза, балалар бииләр).*
- Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә.
Теремкәйдә тычкан яши.
Теремкәйдә куян яши.
Теремкәйдә бүре яши.
Теремкәйгә төлке яши *(хатын-кыз тавышы).*
Теремкәйгә җырлый-җырлый аю килә.
**Аю (ишек шакый):** Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан.
**Куян:** Мин куян.
**Бүре:** Мин бүре.
**Төлке:** Мин төлке.
**Тычкан, куян, бүре, төлке:** Син кем?
**Аю:** Мин аю. Мин зур, матур аю.
**Тычкан, куян, бүре, төлке:** Әйдә, кил монда.
**Аю (керә):** Мин җырлыйм. Әйдәгез, җырлыйбыз *(озын пауза, балалар кушылып җырлый).*
**Музыка. Балалар белән бергә җырлыйлар.**
Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,

Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
- Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә,
Теремкәйдә тычкан яши, пи-пи-пи.
Теремкәйдә куян яши. Мин куян.
Теремкәйдә бүре яши. Мин бүре.
Теремкәйдә төлке яши. Мин төлке.
Теремкәйдә аю яши. Мин аю.
Алар бик дус *(хатын-кыз тавышы).*
**Күңелле музыка. Бииләр.**
**Тема: Өстәл театры “Кем нәрсә ярата?”**
**65 нче кисәк (55 нче тема).**
- Я вам расскажу сказку «Кто что любит» -«Кем нәрсә ярата?» *(хатын-кыз тавышы).*
**Кошлар сайраган тавышлар ишетелә. Әтәч канат кагып кычкыра.**
**Әтәч:** Кикри-күк, кикри-күк *(кыска пауза)* Ко-ко-ко.
**Песи киерелеп:** Мияу-мияу-мияу.
**Песи:** Хәерле көн, әтәч.
**Әтәч:** Хәерле көн, песи.
**Песи:** Хәлләр ничек, әтәч?
**Әтәч:** Әйбәт. Рәхмәт. Ә синең хәлләрең ничек?
**Эт йөгереп килә:** Һау-һау-һау. Исәнме, әтәч. Исәнме, песи.
**Әтәч белән песи:** Исәнме, эт.
**Эт:** Кәҗә кая?
**Әтәч белән песи:** Әнә, кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.
**Эт:** Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?
**Песи:** Мин сөт яратам. Сөт тәмле. Әтәч, син нәрсә яратасың?
**Әтәч:** Мин ботка яратам. Ботка тәмле.
**Кәҗә:** Исәнмесез. Хәерле көн. Хәлләр ничек?
**Бергә:** Әйбәт.
**Кәҗә:** Мин кәбестә ашыйм. Кәбестә бик тәмле. Акбай, мә кәбестә, аша. Кәбестә тәмле.
**Акбай:** Юк, мин ипи яратам. Син кәбестә аша. Ипи кирәк.
**Кәҗә:** Мә, ипи, аша.
**Акбай:** Рәхмәт. Ипи тәмле.
**Песи:** Мин сөт яратам. Сөт юк.
**Кәҗә:** Сөт бар. Песи, кил монда. Сөт ал, эч.
**Песи сөт эчә:** Мин сөт эчәм. Сөт тәмле. Әтәч, кил монда, сөт эч.
**Әтәч:** Юк, мин сөт яратмыйм. Мин ботка яратам. Ботка юк.
**Кәҗә:** Ботка бар, кәрзиндә. Әтәч, кил монда. Мә ботка, аша.
**Әтәч:** Зур рәхмәт. Ботка бик тәмле. Мә, кәҗә, ботка аша.
**Кәҗә:** Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.
**Әтәч:** Юк, ботка тәмле.
**Песи:** Юк, сөт тәмле.
**Эт:** Юк, ипи тәмле.

**Кыз килеп чыга:** Ипи тәмле, сөт тәмле, ботка тәмле, кәбестә тәмле. Мин ипи, ботка, кәбестә яратам.
**Бергә җырлап, бииләр.**
Ипи тәмле,
Сөт тәмле,
Ботка тәмле,
Кәбестә тәмле.

**Тема: "Кем нәрсә ярата?" әкиятен сәхнәләштерү.**
**66 нчы кисәк (56 нчы тема).**
***Җыр.***
Ипи тәмле,
Сөт тәмле,
Ботка тәмле,
Кәбестә тәмле.

**Тема: "Белем иленә сәяхәт".**
**67 нче кисәк (58 нче тема).**
- Какая красивая книга. Ребята, эта книга волшебная. В каждой ее страничке таится секрет. волшебство.  Давайте, посмотрим вместе,  какая тайна спрятано в этой волшебной книге *(ир-ат тавышы).*

**68 нче кисәк (58 нче тема).**
**Акбай:** Бу әни. Әни матур, әйбәт, зур. Бу ипи. Әни ипи ашый. Ипи тәмле. Әни ипи ярата.
**Мияу:** Бу әти. Әти зур, матур, әйбәт. Бу сөт. Әти сөт эчә. Сөт тәмле. Әти сөт ярата.

**69 нчы кисәк (58 нче тема).**
***Җыр.***
Мин куян, мин куян,
Зур куян, матур куян.
Мин тычкан, мин тычкан,
Кечкенә, матур тычкан.

**Тема: "Могҗизалар кыры".**
**70 нче кисәк (59 нчы тема).**
***Хат.***
- Дорогие ребята! Я Вас приглашаю на выпускной бал, который состоится в моем королевстве «Знаний».  Но для этого вы должны выполнить все мои задания. Мои задания в этом волшебном сундучке. Если все задания выполните успешно, вы непременно попадете в мое королевство, где говорят на красивом – татарском языке. Желаю Вам удачи, и с нетерпением жду Вас у себя» *(хатын-кыз тавышы).*

**71 нче кисәк (59 нчы тема).**
-Ребята, молодцы. Вы выполнили все мои задания. Добро пожаловать в мое королевство “Знаний”, где говорят на красивом татарском языке. Желаю вам удачи! *(хатын-кыз тавышы).*

**Мультсюжетлар.**
**“Минем өем”**
**(Мой дом) проекты (4-5 лет).**

**1. Мультфильм «Әйдә дуслашыйк» (9 тема).**
Өй күренеше. Ишек алды. Ишекне ачып песи баскыч төбенә чыга: Мияу-мияу(һәрәкәт) Эт оясы янына бара. Эт оясында йоклый(тавыш) Песи эт оясын шакый. Эт: Һау-һау, кем анда? Песи: Мияу-мияу, мин песи, мин Мияу. Син кем?
Эт оясыннан чыга. Эт: исәнме Мияу, мин эт – мин Акбай, хәлләр ничек? Песи: әйбәт, әйдә уйныйбыз.(уйныйлар). Тәрәзәдән кыз күренә: Мияу, кил монда. Мияу: Акбай сау бул! Эт: сау бул Мияу.

**2. Мультфильм «Качышлы уйныйбыз» (12 тема).**
Ишек алды күренеше (агачлар, үләннәр, эт оясы, өй, ишек төбе, һ.б.) Эт оясыннан чыга, як-ягына карый, гаилә әгъзалары төрле эш белән шөгыльләнә, ләкин йөзләре күренми.(Әни кер элә, әти гәҗит укый, кыз чәчәк түтәле артында, песинең койрыгы күренеп тора, малай зур туп тоткан) Эт иснәп бара, әни янына туктап сорый: син кыз? – юк, мин әни! (һәр персонаж янына килеп шул ук сорауны бирә. Җаваплар “Әйе” “Юк” вариантында (Әйе, мин әни. Юк, мин малай)
Мияуны иң соңыннан таба, син Мияу? - әйе, мин Мияу!
Әйдә уйныйбыз (кочаклашалар, сөенәләр, уйныйлар, бииләр)

**3. Мультфильм «Шалкан әкияте буенча» ( 18 тема).**
Персонажлар: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт, песи.
Сүзлек: Әби кил монда, әти кил монда, һ.б.
Шалканны тартып чыгаргач шатланалар, бию көенә бииләр.

**4. Мультфильм «Безнең кунаклар» ( 21 тема).**
(Әби белән бабай кунакка килә). Ишек алды(котедж) күренеше. Песи йөри. Беседка, өстәл белән урындык. Капка шакыйлар. Эт өрә. Өйдән кыз чыга.
- Кем анда?
- Мин әби.
- Мин бабай
- Керегез (капканы ачып, кочаклап исәнләшә)
- Исәнме әби, исәнме бабай.
- Хәлләр ничек?

- Әйбәт.
- Әйдә әби, кил монда. Утыр.
- Әйдә бабай, кил монда. Утыр. (кыз чакыра)
- Әти, әни, Азат килегез монда! (өйдән чыгалар, исәнләшеп күрешәләр)

Әби өстәлгә чиккән сөлгедән авыл ипиен куя.

- Балалар мә сезгә тәмле ипи.

Бабай өстәлгә кәрзин белән җимешләр куя (алма, груша, лимон, слива) һәм гаилә әгъзаларын сыйлыйлар.

- Мә, Азат алма
- Рәхмәт.

Җыр "Алма"
Алма, алма алмакай.
Бигрәк матур алмакай.
Ипи, ипи ипекәй.
Бигрәк тәмле ипекәй.

**5. Мультфильм «Тәмле» кибетендә» ( 27 тема).**

Персонаж: Авылдан килгән әби белән бабайны кыз белән малай "Бәхетле" кибетенә алып баралар, эт белән песи. Эскалатор белән менәләр. Кафега тукталалар. Мороҗеное, сок, чәй эчәләр.Ашамлыклар алып кайтып китәләр.
(лексика: ипи, сөт, чәй, груша, торт бир әле, рәхмәт)

**6. Мультфильм «Азат кунак чакыра» (30 тема).**

Персонажлар Азат, Алсу, дуслары (балалар)
Телефоннан кунакка чакыру:

- Исәнме, Булат, мин Азат, миңа кунакка кил.
- Исәнме Азат, кунакка киләм, рәхмәт.

Шул рәвешле, дусларын кунакка чакыралар. Соңыннан барысы кунакка җыелышып киләләр, бәйрәм итәләр. Азат белән Алсу кунакларны сыйлыйлар:

- Мә, чәй эч!
- Чәй тәмле!
- Мә, чәй эч!
- Юк, мин сок эчәм.
- Рәхмәт, тәмле булды!

Балалар җырлы-биюле уен уйныйлар. Саубуллашып китәләр.
Мин дә бик матур малай.
Мин дә бик матур малай.
Әйе шул, әйе шул
Мин дә бик матур малай!

**7. Мультфильм «Карусельга сәяхәт» (36 тема).**
Персонажлар: (өйрәнгән уенчыклар: курчак(Ләйлә) песиләр, этләр, туплар, куяннар, зур машина, уенчыклар, өй күренеше)
Тәрәзәләрдән уенчыклар карап тора. Кычкыртып машина килеп туктый.
Уенчыкларны "Чакыра". Уенчыклар шатланып, өйдән чыгып машинага утыралар, паркка киләләр. Җырлый-җырлый баралар.
Җыр: Карагыз, карагыз машинада барабыз.
Курчак, куян, песи, туп
Карусельда уйнарбыз.
Һау-һау (эт өрә), хоп-хоп-хоп (уенчыклар кул чабалар)
Мияу-мияу (песи кычкыра), тып-тып-тып (тыпырдыйлар)
Паркка барып җитәләр. Карусель җыр белән каршы ала.
Җыр: Әллә-лә, әллә-лә, каруселләр әйләнә.
Матур туплар әйләнә.
Зур-зур песи әйләнә.
Кечкенә эт әйләнә.
Уенчыклар карусельда әйләнәләр.

**8. Мультфильм «Уенчыклар үпкәләде» (42 тема).**
Персонажлар: Аю, куян, курчак, машина, туп.
Әни, малай, эт, песи.
Өй эче күренеше. Уен бүлмәсе.
Малай уенчыклар белән уйнап утыра. Әнисе кереп йокларга вакыт җиткәнен, уенчыкларны җыярга кирәклеген әйтә.
Малай уенчыкларны таратып калдыра, кулын селтәп йокларга китә.
Уенчыклар үпкәләп, төрле җиргә качалар. Иртән торгач, Азат уенчыкларын эзли башлый, эт һәм песи аңа булыша.
Уенчыклар юк: куян юк, аю юк һ.б.
<u>**Азат**</u>: Куян , кил монда! (Шул рәвешле калган барлык уенчыклар да чакырыла).
<u>**Азат**</u>: Эт, песи, кил монда!
Бергәләшеп уенчыкларны эзләп табып алалар.
<u>**Азат**</u>: Рәхмәт!

**9. Мультфильм «Күңелле уеннар» (45 тема).**
Балалар төрле уеннар уйныйлар.
Персонажлар: Азат, Алсу, Акбай, Мияу, малай, кыз, эт, песи, уенчыклар.
Лексика: Уйна, сикер, кил монда, утыр, аша, эч.
Җыр: Туп, туп, матур туп.
Сикер, сикер матур туп.
Бер, ике, өч, сикер, сикер матур туп.

**10. Мультфильм «Акбай һәм Мияу маҗаралары» (48 тема).**
Персонажлар: Әни, эт, песи, Азат
Урам күренеше.

Акбай белән Мияу ауный-ауный уйныйлар. Яңгыр ява башлый, алар уйнауларын һаман дәвам итәләр. Пычранып бетәләр. Азат аларны өйгә чакыра.
-Акбай, кил монда!
-Мияу, кил монда!
Мияу белән Акбай чаба-чаба юыну бүлмәсенә кереп китәләр. Идәндә пычрак эзләре кала.
**Әни**: Кем пычратты?
**Мияу:** Акбай!
**Акбай:** Мияу!
Алар бер-берсенә карашалар.
**Мияу:** Син пычрак!
**Акбай:** Юк, син пычрак!
Күзгедән карашалар, бармаклары белән күзгегә төртеп: Пычрак! – диешәләр.
Юынып алганнан соң бере-берсенә: Чиста! –диешәләр.

**10. Мультфильм «Уйный-уйный саныйбыз» (54 тема).**
Азат белән Алсу маҗаралары. (Саннарны куллану).
Азат белән Алсу юлларында очраган әйберләрне санап йөриләр. Җырласалар да була.

**11. Мультфильм «Күңелле ял итәбез» (57 тема).**
Персонажлар: әни, әти, бабай, әби, эт, песи, аю, куян.
Әти-әни кәрзингә ашамлыклар салып, ә кыз белән малай уенчыкларын җыйнап алып чыгалар.
Күренеш: Гаилә әгъзалары һәм эт, песи микроавтобуска төялеп, кәрзиннәрен алып урманга китәләр. Юлда барганда җырлый-җырлый баралар.
Сәяхәткә китәбез
Күңелле ял итәбез.
Әллә -лә, әллә-лә
Күңелле ял итәрбез.
Барысы да урманның хозурлыгына сокланып баралар. Урманда аю, куян агач артларыннан аларга зур кызыксыну белән карыйлар. Балалар: Куян! Аю!- дип аларны әти-әни, әби-бабайларына күрсәтәләр, һәм аларны фотога тәшереп-төшереп алалар. Аланга туктап ашау мөмкинлекләре тудыргач, аю белән куянны чакыралар. (Аю, кил монда! Утыр! Куян сикер! Һ.б.) барысы бергә уйнап, сыйланып күңел ачалар.

## Мультсюжетлар.
## “Уйный – уйный үсәбез”
## (Растём играя) проекты (5-6 лет).

**1. Мультфильм “Шалкан” (3 нче тема).**

*Персонажлар:* бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт, песи.
*Лексика:* Әби кил монда, әти кил монда, әни кил монда, малай кил монда, кыз кил монда,
песи кил монда, эт кил монда.
*Күренеш:* Матур өй, яшелчә бакчасында түтәлләр. Бабай шалкан түтәле янында. Түтәлдә зур шалкан үскән.
Мульфильм "Шалкан" әкияте буенча.
*Эчтәлек:*
Бабай яшелчә бакчасында түтәлләр карап йөри. Менә ул шалкан түтәле янына килә дә, зур үскән шалканны күреп шакката.
**Бабай:** Сөбеханалла! Сөбеханалла! Шундый зур шалкан! Кая әле, кая әле, тартып карыйм булмаса. (бабай шалканны тартып карый, шалкан чыкмый) Юк, булмый.
Ярдәмгә әбине, әтине, әнине, малайны, кызны, этне, песине чакыра.
(Барлык персонажларны да төрләндерергә).
Шалканны тартып чыгаргач шатланалар, татар халык бию көенә бииләр.

**2. Мультфильм "Баллы кишер" (6 нчы тема).**
*Персонажлар:* бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт, песи.
*Лексика:* Әби кил монда, әти кил монда, әни кил монда, малай кил монда, кыз кил монда,
песи кил монда, эт кил монда, кишер зур, кишер тәмле.
*Күренеш:* Матур өй. Өй янында яшелчә бакчасы, анда кишер, кыяр, суган, бәрәңге, түтәлләре. Бабай шалкан түтәле янында. Түтәлдә зур кишер үскән.
*Эчтәлек:*
Яшелчә бакчасы. Түтәлләр.
Бабай, эт һәм песи түтәлләргә су сибәләр. Түтәлләрдә бер-бер артлы яшелчәләр үсеп чыга: бәрәңге, кыяр, суган, кишер. Бабай кишер түтәле янына килә. Зур үскән бер кишерне күреп шакката. Тартып карый.
**Бабай:** 1, 2, 3, 4, 5. (Тартып карый, чыгара алмый). Юк, булмый. (Әбине чакыра): Әби, кил монда.
**Әби:** Кем анда? Нәрсә булды?
**Бабай:** Кишер зур. Тартып булмый. Әйдә булыш.
**Әби:** И – и – и, бабай! Әйдә, тартыйк кишерне!
**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.
**Әби:** Юк, бабай, булмый. Әтине чакырыйм. Әти, кил монда.
**Әти**(килә, ул да исе китеп): Ай – яй, кишер бигрәк зур үскән! Әйдә, бергә тартыйк.
**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.
**Әти:** Юк, булмый. Бик зур. (әнине чакыра) Әни, кил монда.
**Әни:** Нәрсә булды? (Кишерне күреп, гаҗәпләнә): Нинди зур кишер! Әйдә, бергә тартыйк.
**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.

Тарталар, тарталар, тартып чыгара алмыйлар. Шул үрнәктә малай, кыз, эт, песине чакырыла. Кишерне тартып чыгаргач, түгәрәккә басып җыр җырлыйлар:

Кишер, кишер,
Тәмле кишер.
Кишер, кишер,
Баллы кишер
Кишер, кишер,
Зур кишер.
Әйе шул, әйе шул
Тәмле, баллы, зур кишер!

**3. Мультфильм “Уйный-уйный эшлибез” (15 нче тема).**
Персонажлар: Акбай, Мияу. кишер, кыяр, суган, бәрәңге, кәбестә битлекләре кигән балалар яисә кишер, кыяр, суган, бәрәңге, кәбестә персонаж ролен ә керәләр.

Лексика: Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә,
Күренеш: Җәй көне. Өй, эт оясы. Бакча күренеше. Бакчада түтәлләр (кишер, кыяр, суган, бәрәңге, кәбестә).
Эчтәлек: Мияу өйдән кәрзин тотып чыга, як-ягына карана, эзләнә:
**Мияу:** Акбай, Акбай, кил монда *(Акбай күренми).*
- Акбай юк.

Оя янына бара, шакый:
- Акбай.

Акбай оя эченнән:
**Акбай:** Кем анда?
**Мияу:** Бу мин, Мияу. Кил монда.
Эт оясыннан йокыдан уянып бетмәгән Акбай башын чыгара:
**Акбай:** Нәрсә кирәк?
**Мияу:** Әйдә бакчага барабыз.
**Акбай:** Кая барабыз?
**Мияу:** Бак-ча-га (сузып, иҗекләп бакча ягына күрсәтә).
Акбай теләр-теләмәс кенә чыга, киерелә, сикергәли, уянып бетә.
**Акбай:** Әйдә Мияу, киттек.
Җитәкләшеп, җырлый-җырлый китәләр:

Бар матур, зур бакча,
Анда кишер үсә.
Кыяр, кәбестә үсә, *(күрсәтеп)*
Бәрәңге, суган үсә.

Бакчага килеп җитәләр. Түтәлләрне карап чыгалар. Яшелчәләрнең күплегенә, мул булып үсүенә шатланалар. Җырлый-җырлый яшелчәләрне чакыралар:
1)Бар матур, зур бакча,
Анда кишер үсә.

Менә шундый кишер зур, *(зур кишергә)*
Менә шундый кечкенә. *(кечкенә кишергә)*
Кишер-кишер кил әле,
Биеп, биеп кит әле. *(түтәлдән 1 зур, 1 кечкенә кишерләр чыгалар, бииләр).*
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле. *(кәрзингә күрсәтәләр, кишерләр кәрзингә сикереп кереп утыралар)*
2)Бар матур, зур бакча,
Анда кыяр үсә.
Менә шундый кыяр зур, *(зур кыярга)*
Менә шундый кечкенә. *(кечкенә кыярга)*
Кыяр-кыяр кил әле,
Биеп, биеп кит әле. *(түтәлдән 1 зур, 1 кечкенә кыярлар чыгалар, бииләр).*
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле. *(кәрзингә күрсәтәләр, кыярлар кәрзингә сикереп кереп утыралар)*
3)Бар матур, зур бакча,
Анда суган үсә.
Менә шундый суган зур, *(зур суганга)*
Менә шундый кечкенә. *(кечкенә суганга)*
Суган-суган кил әле,
Биеп, биеп кит әле. *(түтәлдән 1 зур, 1 кечкенә суганнар чыгалар, бииләр).*
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле. *(кәрзингә күрсәтәләр, суганнар кәрзингә сикереп кереп утыралар)*
4)Бар матур, зур бакча,
Анда кәбестә үсә.
Менә шундый кәбестә зур, *(зур кәбестәгә)*
Менә шундый кәбестә. *(кечкенә кәбестәгә)*
Кәбестә кил әле,
Биеп, биеп кит әле. *(түтәлдән 1 зур, 1 кечкенә кишер чыгалар, бииләр).*
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле. *(кәрзингә күрсәтәләр, кишерләр кәрзингә сикереп кереп утыралар)*
5)Бар матур, зур бакча,
Анда кишер үсә.
Менә шундый кишер зур, *(зур кишергә)*
Менә шундый кечкенә. *(кечкенә кишергә)*
Кишер-кишер кил әле,
Биеп, биеп кит әле. *(түтәлдән 1 зур, 1 кечкенә кишер чыгалар, бииләр).*
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле. *(кәрзингә күрсәтәләр, кишерләр кәрзингә сикереп кереп утыралар)*

**4. Мультфильм “Юл маҗаралары” (18 нче тема).**

*Персонажлар:* кызыл, сары, яшел төстәге машиналар, светофор, эт Акбай, песи Мияу.
*Лексика*: Сары, кызыл, яшел.
*Күренеш:* Төсләрне үзе әйтә торган светфор: Яшел – бар! Сары - Әзерлән! Кызыл – Тукта! Юлда төрле төстәге машиналар. Йөк машиналары яшелчәләр төягәннәр. Мияу белән Акбай юлның ике ягында басып торалар. Мияуның кулында туңдырмалар.
*Эчтәлек*:
Светофор кызыл утка туктамаган машиналарны "тотып" туктата. Сары утка әзерләнергә куша, яшел ут янганда китә алмый торган машиналарга ярдәм итә.
Акбай белән Мияу юлның ике ягында басып торалар. Мияу киосктан туңдырма алган. Светофорда кызыл ут янганда Мияу Акбайны чакыра.
**Мияу:** Акбай, кил монда! Туңдырма аша!
**Акбай:** Юк, кызыл ут (төртеп күрсәтә), анда машина. Машина күп, куркам.
**Сетофор:** *(Светофор елмаеп яшел күзен кыса да, Акбайны уздыра)* Акбай, әйдә, сиңа юл ачык!
**Акбай:** Рәхмәт, светофор!
**Мияу:** Акбай, кил монда, утыр. Мә, аша!
**Акбай:** Тәмле, баллы. Рәхмәт Мияу!
*Чәчәк клумбасын күзәтәләр.*
**Мияу:** Кара, нинди матур чәчәкләр!
**Акбай:** Кызыл чәчәк, сары чәчәк.
*Чәчәкләргә төрле төстәге күбәләкләр куна.*
**Мияу:** Ай - яй! Нинди матур күбәләкләр!
**Акбай:** Кызыл, сары, яшел күбәләкләр.
*Бергә шатланыша – шатланыша җырлыйлар:*

Сары, кызыл чәчәкләр,
Ай – яй матур чәчәкләр
Әйе шул, әйе шул,
Сары, кызыл чәчәкләр.

**5. Мультфильм "Кем эшләми, шул ашамый" (21 нче тема).**
*Персонажлар:* әти, әни, әби, бабай, Азат исемле малай, Алсу исемле кыз, эт Акбай, песи Мияу.
*Лексика:* алма, кишер, кыяр, помидор, суган, кәбестә, сөт, кызыл, сары, яшел, ал, җый, кил монда, күп, 1, 2, 3, 4, 5 – санау, зур, кечкенә, баллы, тәмле.
*Күренеш:* Өй. Бакча. Алмагачта алмалар. Кишер, кыяр, суган, кәбестә, помидор, түтәлләре. Әти, әни, әби, бабай, Азат, Алсу, Акбай - барысы да эшлиләр. Песи эшләми, ялкауланып йөри, түтәлләр арасында йөгерә, кәрзиннәрне аудара.
*Эчтәлек:* Песинең уйнап йөрүен күреп, аны чакыралар.
**Акбай:** Мияу, кил монда. Кишер җый.

**Песи:** Юк, мин зур түгел, мин кечкенә. Мин уйныйм.
**Азат:** Мияу, кил монда. Кыяр җый.
**Песи:** Юк, кыяр тәмле түгел, сөт тәмле. Мин сөт яратам.
**Алсу:** Мияу, кил монда. Алма җый. Алма кү – ү – үп, баллы, тәмле.
**Песи:** Юк, мин уйныйм. Син җый.
*Акбай Алсу янына килә, алма җыярга ярдәм итә*
**Алсу:** Сикер – сикер, Акбай, алма ал. Акбай әйбәт, яхшы. Рәхмәт, Акбай. Кил, монда утыр.
Эш беткәч, барысы да беседкада ашарга утыралар. Мияу тәмле исне сизеп беседка янына килә. Аңа игътибар итмиләр.
**Бабай:** Кем эшләми, шул ашамый – Кто не работает, тот ни ест.

**6. Мультфильм "Аш бүлмәсе" (27 нче тема).**
*Персонажлар*: әти, әни, Азат исемле малай, Алсу исемле кыз, әби, бабай, эт Акбай, песи Мияу.
*Лексика:* ипи, сөт, чәй, аш, ботка, чәк-чәк, өчпочмак, гөбәдия.
*Күренеш:* Өйдә аш бүлмәсе. Әби, белән бабай өстәл артында утыралар, әни ашарга пешерә, Азат белән Алсу өстәл әзерлиләр. Мияу сырпаланып йөри. Акбай үз тәлинкәсе янында ашарга көтеп йөри.
*Эчтәлек:* Барысы да өстәл артынада ашамлыклар турында сөйләшәләр. Алсу өстәлгә кызыл, сары, яшел алмалар куя.
**Алсу:** Алма күп, кызыл, сары, яшел. Алма тәмле, баллы,
**Бабай:** Ипи бигрәк тәмле.
**Алсу:** Әби (бабай), мә аш аша.
**Әби:** Рәхмәт, кызым. Мин аш яратам
**Азат:** Ә миңа ботка кирәк. Мин ботка яратам. һ.б.
Барысы бергә өстәл артында утырып, мактый – мактый ашыйлар.

**7.Мультфильм "Өч аю". (33 нче тема)**
*Персонажлар:* Өч аю.
*Күренеш:* Урман.
Урмандагы өйдә өч аю яши. Зур аю - әти. Аның исеме Михаил Иванович. Ул калын тавыш белән сөйләшә. Әни аюның исеме Настасья Петровна. Ә бәләкәй аюның исеме Мишутка. Ул нечкә тавыш белән сөйләшә.
Аюлар урман буйлап йөрергә бик яратканнар. Ә аннан соң өйгә кайтып кул-аякларын чиста итеп юганнар да ашарга уырганнар.
Михаил Иванович үзенең тәлинкәсен кулына ала һәм калын тавыш белән әйтә: "Бу тәлинкә".
Настасья Петровна үзенең тәлинкәсен кулына ала һәм бик калын булмаган тавыш белән әйтә: "Бу тәлинкә".
Мишутка үзенең тәлинкәсен кулына ала һәм нечкә тавыш белән әйтә: "Бу тәлинкә".
Михаил Иванович үзенең кашыгын кулына ала һәм калын тавыш белән әйтә: "Бу кашык".

Настасья Петровна үзенең тәлинкәсен кулына ала һәм бик калын булмаган тавыш белән әйтә: “Бу кашык”.
Мишутка үзенең тәлинкәсен кулына ала һәм нечкә тавыш белән алар артыннан кабатлый: “Бу кашык, кашык, кашык”.
Ашап алганнан соң алар ял итәләр.

**8.Мультфильм “Чисталыкта - матурлык” (36 нчы тема).**

*Персонажлар:* курчак Алия, эт Акбай, песи Мияу. Савыт-сабалар: тәлинкәләр, кашыклар, чынаяклар.
*Лексика:* кашык, тәлинкә, чынаяк, чиста, пычрак.
*Күренеш:*
Алия йокысыннан уяна. Аш бүлмәсенә керә. Савыт-сабалар юк. Эзли. Акбай белән Мияудан сорый. Бергәләп савыт-сабаларны эзләргә китәләр. Матур чишмә янында табалар. Юып, алып кайталар.
*Якынча сөйләм үрнәге:*
**Алия:** Акбай, Мияу, кил монда. Тәлинкә (кашык, чынаяк) юк.
**Бергә:** Чынаяк юк, тәлинкә юк, кашык юк. Әйдә эзлибез.
**Савыт-сабалар диалогы:**
- Алия безне юарга онытты. Тәлинкә син пычрак, матур түгел, чиста түгел. (бер-
берсенә әйтәләр).
- Әйдә юынабыз. (Өйдән чыгып, сукмаклар буйлап чишмә янына сөйләшә-сөйләшә киләләр).
Алар артыннан Алия, Акбай, Мияу килеп җитәләр.
**Алия:** Гафу итегез. Килегез монда, мин сезне юам.
Алия савыт-сабаларны юганнан соң алар шатланышып бииләр, кәрзингә сикереп керәләр:
- Мин бик матур, син дә чиста, матур.
Шатланышып өйгә кайтып китәләр.

**9.Мультфильм “Киемнәр кибетендә” (39 нчы тема).**

**Персонажлар:** Әти, әни, Азат исемле малай, Алсу исемле кыз
**Лексика:** күлмәк, чалбар, чиста, матур, яшел, зәңгәр, сары, кызыл.
**Күренеш:** Ишек алды күренеше. Комлыкта балалар уйный: бер бала машинага ком тутыра, икенче бала чиләк белән ком ташый. Читтәрәк бер кыз бала коляска төртеп йөри. Бер малай атынгычта атына. Бер кыз белән бер малай чәчәкләр түтәле янында бөтерелеп очкан күбәләкне күзәтәләр. Аар янында Акбай белән Мияу да бар.
**Эчтәлек:** Кояшлы матур җәйге көн. Балалар ишек алдында уйныйлар. Әти белән әни өй подъездыннан килеп чыгалар.
**Әти:** Азат, кил монда!
**Әни:** Алсу, кил монда! Уйнап утырган балалар арасыннан малай белән кыз йөгереп киләләр.
**Азат:** Әти, кая барабыз?
**Алсу:** Әни, кая барабыз?

**Әти:** Кибеткә барабыз, улым, “Виннипух”ка барабыз.
**Әни:** Кибеткә барабыз, кызым, “Карапуз”га барабыз.
*Кулга – кул тотышып шатлана-шатлана әйләнәләр.*
**Бергә:** Урра! Кибеткә барабыз, “Виннипух”ка барабыз. Урра! Кибеткә барабыз, “Карапуз”га барабыз.
“Карапуз” кибетенә китәләр. Кибеттә һәрберсе үзенә нәрсә кирәклеген әйтәләр.
**Алсу:** Әни, “Карапуз”да нәрсә бар?
**Әни:** Кибетттә күлмәк, чалбар, футболка, сарафан, шорты, майка бар. Кибеттә, сатучыдан сорыйлар.
**Азат:** Миңа матур чалбар кирәк. Матур чалбар бир әле.
**Сатучы**: Мә, матур чалбар.
**Алсу:** Миңа кызыл күлмәк кирәк. Кызыл күлмәк бир әле.
**Сатучы:** Мә, кызыл күлмәк.
Әни: Миңа сары сарафан кирәк.
Сатучы: Мә, сары сарафан..
**Әти:** Миңа зәңгәр футболка кирәк.
**Сатучы:** Мә, зәңгәр футболка.
**Азат:** Әти, “Вннипух”та нәрсә бар?
**Әти:** Туп бар. Машина бар.
**Алсу:** Әни, “Вннипух”та нәрсә бар?
**Әни:** Курчак бар. Шар бар.
**Бергә:** Урра! Кибеткә барабыз, “Виннипух”ка барабыз. Урра!
**Азат:** “Виннипух”ка барабыз. Туп, машина алабыз.
**Алсу:** “Виннипух”ка барабыз. Матур курчак алабыз.
*Кибеттә машина, туп, курчак сорап алалар. Рәхмәт әйтеп җырлый-җырлый кайтып китәләр.*
**Алсу:** Минем күлмәк бик матур,
**Азат:** Минем чалбар бик матур.
**Алсу:** Әйе, шул, әйе шул,
Минем күлмәк бик матур!
**Азат:** Әйе, шул, әйе шул,
Минем чалбар бик матур!
Әйе, шул, әйе шул,
**Әни:** Минем сарафан матур!
**Әти:** Минем футбока матур
**Әни:** Әйе, шул, әйе шул,
Минем сарафан матур!
**Әти**: Әйе, шул, әйе шул,
Минем футболка матур!
**Азат:** Минем машина бик зур,
**Алсу:** Минем курчак кечкенә
**Азат:** Әйе, шул, әйе шул,

Минем машина бик зур,
**Алсу:** Әйе, шул, әйе шул,
Минем курчак кечкенә.
**Бергә**: Әти, рәхмәт! Әни, рәхмәт!
*Әти-шиләрен кочаклыйлар, шатланышып кайтып китәләр.*

**10.Мультфильм “Шаян уенчыклар” (42 нче тема).**

Персонажлар: куян, аю, курчак, кыз, эт, песи.
Лексика: ки, сал, күлмәк, чалбар, пычрак, чиста, матур, яшел, зәңгәр, сары, кызыл.
Күренеш:
Алсу исемле кызның уен бүлмәсе. Уенчыклар киемнәрен дөрес итеп кимәгәннәр: күлмәкнең сәдәфе дөрес эләктерелмәгән, чалбарның бер балагы киелмәгән. Тәртипсезләнәләр. Алсу кереп шаккатып карап тора. Көчле көй яңгырый. Уенчыклар Алсуны күрмиләр, аны ишетмиләр. Алсу музыканы туктата, уенчыклар янына килеп киемнәрен тәртипкә китерергә куша. Бергәләп җырлыйлар.
Эчтәлек:
**Алсу:** Куян, аю, курчак, эт, песи, килегез монда. Бу нәрсә? Ай-яй-яй. Курчак, синең күлмәк пычрак, сал. Мә, чиста, матур, зәңгәр күлмәк ки.*(курчакка күлмәк бирә)*
**Курчак күлмәкне кия:** Әйе шул, күлмәк матур, чиста, зәңгәр. Мин матур кыз.
**Алсу:** Эт, синең чалбар матур түгел, пычрак, сал. Мә, чиста, яшел чалбар ки.*(эткә чалбар бирә)*
**Эт чалбарны кия:** Әйе шул, чалбар чиста, матур, яшел.
Тәртип урнаштырып, матур киемнәр кигәч, бергәләп җырлыйлар:
1. Минем күлмәк бик матур,
Синең күлмәк бик матур.
Әйе шул, әйе шул,
Минем күлмәк бик матур.
2. Минем чалбар бик матур,
Синең чалбар бик матур.
Әйе шул, әйе шул,
Минем чалар бик матур

**\11. Мультфильм “Ни өчен киемнәр югалган?” (45 нче тема)**

Акбай үзенең дусларын туган көнгә чакыра. Мияуның өе. Мияу Акбайга уенчык бүләк әзерли. Акбайның машина белән яратып уйнаганын белеп, “КАМАЗ” машинасын матур коробкага салып әзерләп куя.

Песи Мияу юынып чистарынып утырып тора, үзе җырлый-җырлый мырлый:

“Битемне юам, кулымны юам,
Матурланам, чистарынам.

Мин кунакка барам.”

- Битем матур, кулым чиста. Киттем кунакка.

Барганда сарыкны кереп алырга була. Сарык пычрак, шап-шак кыяфәттә каршы ала.

**Мияу:** Исәнме, Сарык.

**Сарык:** Исәнме, Мияу. Хәлләр ничек?

**Мияу:** Әйбәт. Синең хәлләрең ничек?

**Сарык:** Әйбәт. Син кая барасың?

**Мияу:** Акбайның туган көненә. Юындым, битем матур, кулым чиста. Менә бүләгем. Ә син нигә әзерләнмәдең?

**Сарык:** Ой, мин онытканмын бит кунакка барырга кирәклеген. Әйдә, киттек.

**Мияу:** Син пычрак. Кулың пычрак. Битең пычрак. Ю.

**Сарык:** Юк, нишләп пычрак булсын?!

**Мияу:** Кунакка пычрак килеш бармыйлар. Матур итеп киенеп баралар бит.

**Сарык:** Хәзер матур киемнәремне киям.

Чалбары белән күлмәген эзли-эзли таба алмый.

**Сарык:** Кая китteләр икән?

**Мияу:** Чалбар белән күмәгең син пычрак булган өчен чыгып качканнар.

**Сарык (күңелсезләнеп):** Ярар, юыныйм инде.

Сабын белән битен, кулын юа. Көзгегә карый, җырлый:

Су, су,
Бит, кулны ю.
Чиста су, чиста су,
Ю, ю, ю.

**Көзге елмаеп:** Син матур. Син чиста. Кулың чиста, битең чиста.

Үзенә сокланып карап тора.

**Сарык:** Табылсалар, чиста йөрер идем, чалбарымны үтүкләп эзләр идем, күлмәгемне төреп куяр идем.

Көзге елмаеп куя, урындык артында эленгән күлмәк белән чалбар барлыкка килә.

**Мияу:** Сарык, кара, әнә чалбарың, күлмәгең.

**Сарык (сөенеп):** Бу чалбар. Бу күлмәк. Бит чиста. Кул чиста. Күлмәкне, чалбарны киям, кунакка барам.

Сарык шарлар тотып, Мияу үзенең матур коробкасын тотып Акбайның өенә китәләр.

Акбай аларны каршы ала.

**Мияу:** Хәерле көн. Туган көнең белән Акбай. Мә, машина.

**Акбай:** Рәхмәт, Мияу.

**Сарык:** Акбай, мә сиңа матур шарлар.

**Акбай:** Рәхмәт, Сарык. Син матур, син чиста.

Сарык кәнагатьлек белдереп елмая, алар түгәрәккә басып, җырлап, көлешеп өстәл янына сыйланырга кереп китәләр.

**12.Мультфильм “Маша һәм өч аю”. (48 нче тема)**

*<u>Персонажлар:</u>* Өч аю, Маша.
*<u>Лексика</u>*: Өч, аю, яшел, сары, зәңгәр, кашык, тәлинкә, чынаяк, өстәл, урындык, карават.
*<u>Күренеш:</u>* Урман. Маша адашып урманда йөри. Ул аюлар өен күрә. Өй янына килеп, Маша ишек шакый.
**Маша:** Бу өйдә кем яши? *(җавап бирүче булмагач, ишекне ачып өйгә уза)*
**Аш бүлмәсе күренеше:** зур, кечкенә урындыклар, өстәл. Өстәлдә төрле зурлыктагы 3
тәлинкә, 3 кашык, 3 чынаяк. Маша урындыкларга утырып карый. Зур урындыкка
утырып:
- Зур урындык әйбәт түгел.
Өстәлдә тәлинкә белән аш күрә:
- Миңа аш кирәкми, мин ботка яратам.
Маша кечкенә урындыкка утырып карый:
- Кечкенә урындык әйбәт, матур.
Өстәлдә тәлинкә белән ботка күрә:
- О-о-о! Бу ботка. Мин ботка яратам.
Кечкенә кашык эзли:
- Кечкенә кашык кирәк!
Ботканы ашап карый:
- Ботка тәмле. Мин ботка яратам.
Урындыкта тирбәлә-тирбәлә ботка ашый, егылып төшә.
**Йокы бүлмәсенә керә.**
Бүлмәдә төрле төстәге өч карават. Маша зур яшел караватка ята.
- Яшел карават зур. *(Ризасызлык белдерә, сикереп төшеп сары караватка ята.)*
- Сары карават зур, кечкенә түгел. *(Сикереп төшеп зәңгәр, кечкенә караватка ята.)*
- Зәңгәр карават кечкенә, матур, чиста. Бу минем карават. Мин монда йоклыйм.
- Мин кеченә, зәңгәр караватны яратам. Маша караватка менеп ята.
*Ул йоклап китүгә аюлар кайтып керә.*
**Әти аю белән әни аю бергә сорыйлар:** Кем минем урындыкта утырды? Кем минем ашны ашады?!
**Мишутка:**
Ботка юк! Кем минем ботканы ашады, урындыкта кем утырды?!
Аюлар йокы бүлмәсенә кереп китәләр.
**Настасья Петровна белән Михаил Иванович:** Матур кыз йоклый, тс – с – с!
**Мишутка:** Кем минем караватта ята?!
Мишутка тавышына Маша уяна.
**Аюлар**(сорый): Син кем?
**Маша:** Мин Маша.
Аюлар аңа юл күрсәтәләр.

**Маша:** Рәхмәт. Сау булыгыз!
**Аюлар:** Сау бул, Маша(кул болгап озаталар)

### 13. Мультфильм “Туган көн”. (51 нче тема)

*Персонажлар*: эт, песи, куян, аю.
*Лексика:* туп, машина, самолет, курчак, нәрсә кирәк? чәй, сөт, ак ипи, кызыл, сары, яшел алма, зәңгәр. Мин яратам. Рәхмәт. Азат, кер. Алия, кер. Мияу, кер. Акбай, кер. Кил, утыр.
*Күренеш:* Бәйрәмчә матур итеп бизәлгән Алиянең бүлмәсе. Күңелле татар музыкасы яңгырый. Алия дә матур итеп киенгән, ул иптәшләрен каршылый. Дуслары Алиягә бүләкләр алып килгәннәр. Алияне туган кәне белән котлап, балалар уенчыкларын Алиягә бүләк итәләр.
*Эчтәлек:* Ишек шакыйлар.
**Алия:** Кем анда?
**Балалар:** Исәнме, Алия.
**Алия:** Исәнмесез. Кер, Азат. Кер, Алсу. Мияу, кер. Акбай, кер.
**Азат:** Мә, Алия, матур туп.
**Алия:** Рәхмәт, Азат. Туп матур. Кил, монда, утыр.
**Алсу:** Мә, Алия, кызыл машина. Машина матур.
**Алия:** Рәхмәт, Алсу. Әйе, машина кызыл, матур. Кил, монда, утыр.
**Мияу:** Мә, Алия, яшел туп.
**Алия:** Рәхмәт, Мияу. Туп матур. Кил, утыр.
**Акбай:** Мә, Алия, матур курчак.
**Алия:** Рәхмәт, Абай. Кил, утыр.
*Алия иптәшләрен сыйлау өчен туган көненә күп итеп тәмле ризыклар әзерләнгән.*
**Алия:** Маша, сиңа нәрсә кирәк?
**Маша:** Чәй кирәк.
**Алия:** Мә, чәй. Эч.
**Маша:** Рәхмәт, чәй баллы. Мин чәй яратам.
**Алия:** Саша, сиңа нәрсә кирәк?
**Саша:** Алма кирәк. Мин алма яратам.
**Алия:** Нинди алма?
**Саша:** Кызыл алма.
**Алия:** Ал, кызыл алма. Аша.
**Саша:** Рәхмәт. Кызыл алма баллы.
*Алия үзенең дуслары белән өстәл артында сыйланалар. Ашамлыкларны мактыйлар:*
- Алма баллы. Мин алма яратам.
- Аш тәмле. Мин аш яратам.
- Салат тәмле. Мин салат яратам.
- Ботка тәмле. Мин ботка яратам.
- Мороженое баллы. Мин мороженое яратам.

*Алиянең дуслары да буш килмәгәннәр. Хуш исле ак ипи алып килгәннәр. Алар Алиягә ипине бирәләр. Алия уртада, балалар түгәрәккә басып,“Ак калач” җырлы-биюле уенын уйныйлар.*
Алиянең туган көненә
Без пешердек ак ипи.
Менә шундый ипи зур,
Менә шундый кечкенә,
Менә шундый бик тәмле,
Менә шундый бик баллы.
Әйе шул, әйе шул,
Әйе шул ипи тәмле.
*Соңыннан барысы бергә бииләр.*

### 14.Мультфильм “Кем, нәрсә ярата?” (54 нче тема)

<u>*Персонажлар*</u>**:** эт, песи, куян, аю.
<u>*Лексика:*</u> кызыл, сары, яшел, алма, сөт, аш, кишер, тәмле, баллы, нинди кирәк?, аю, песи, эт, куян.
<u>*Күренеш:*</u> Эт белән песи болында уйнап йөриләр. Шул вакыт алар куян белән аюны очраталар.
<u>*Эчтәлек:*</u>
**Эт, песи:** Син кем?
**Аю:** Мин аю.
**Куян:** Мин куян. Ә син кем?
**Песи:** Мин песи – Мияу.
**Эт:** Ә мин эт – Акбай.
Сөйләшә башлыйлар.
**Песи:** Куян, син нәрсә яратасың?
**Куян:** Мин, кишер яратам.
**Песи:** Мә, куян, кишер аша.
**Куян:** Рәхмәт. Кишер тәмле. Мә, песи, кишер аша.
**Песи:** Юк-юк, мин сөт яратам, сөт тәмле.
**Куян:** Мә, сөт, эч.
**Песи:** Рәхмәт, сөт тәмле (песи, сөтне аюга бирә). Мә, аю, сөт эч.
**Аю:** Юк-юк, мин алма яратам, алма тәмле,баллы.
**Песи:** Монда алма күп, нинди алма кирәк?
**Аю:** Кызыл алма кирәк.
**Песи:**(сары алма бирә) Мә, кызыл алма.
**Аю:** Юк, бу сары алма, миңа кызыл алма кирәк.
**Песи:** Мә, ике кызыл алма, аша.
**Аю:** Рәхмәт. (Аю бер алманы ашый, икенче алманы эткә бирә) Мә, Акбай, алма аша.
**Эт:** Юк, мин аш яратам, ботка яратам.
**Аю:** Мә, эт, ботка аша.
**Эт:** Рәхмәт, тәмле.

**15. Мультфильм “Сабантуй бәйрәме”.**
*Персонажлар:* Милли татар киемнәре кигән әби, бабай, әти, әни, Алсу исемле кыз, Азат исемле малай, Акбай, Мияу, балалар.
*Лексика:* “Йөгер”, “Сикер”, “Уйна”, “Җырла”, “Бие”.
*Күренеш:* Сабантуй мәйданы. Мәйданда уеннар, ярышлар уздырыла.
*Эчтәлек:*
Татар музыкасы уйнап тора. Балалар “Сабантуй” җырын җырлап бәйрәмчә бизәлгән Сабантуй мәйданына узалар. Тәрбияче тантаналы рәшвештә бәйрәмне ачып җибәрә. Шигырьләр укыла. Уеннарны тәрбияче оештыра һәм командаларын татарча бирә:
“Йөгер”, “Сикер”, “Уйна”, “Җырла”, “Бие”.

1. “Капчык киеп сикерү”.
2. “Агач кашыкка йомырка салып йөгерү”.
3. “Ат чабышы”.
4. “Чүлмәк вату”.

Татар биюе
Җиңүчеләргә бүләкләр бирелә.
Сабантуй җыры
1. Карагыз, карагыз,
Сабантуйга барабыз.
Сабантуйга барабыз,
Уйнап бүләк алабыз.
2. Сабантуйга барабыз,
Сикерәбез, чабабыз.
Җырлап, биеп алабыз,
Уйлап бүләк алабыз.

**Мультсюжетлар.**
**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”**
**(Мы уже теперь большие, дорога ведет нас в школу) проекты (6-7 лет).**

**1 Мультфильм (3 нче шөгыль) “Мияу адашкан”**
**Персонажлар:** Мияу, Куян, Әтәч, Үрдәк, Әни-Мияу.
**Лексик доза:** Син кем? Син кая барасың? Бу нәрсә? Хәерле көн, үрдәк, әтәч.
**Күренеш:** Кояшлы матур көнне Мияу үзенең дуслары белән уйнарга чыгып китә. Уйный торгач ул үзе дә сизмәстән өеннән ерккарак китә. Дуслары өйләренә таралып беткәч, ул үзенең адашканын аңлый. Мияу: “Әни!”, дип елый ук башлый.Үлән кыштырдаган тавышны ишетеп: “Әни!”, дип сөенеп тавышка йөгереп китә. Куянны күргәч, аптырый.
**Эчтәлек:**
**Мияу:** Син кем?
**Куян:** Мин куян. Син кем?
**Мияу:** Мин песи. Мин Мияу.

**Куян:** Син кая барасың?
**Мияу:** Өйгә. Мин кайта белмим ***(елап җибәрә).***

Шунда "Кикрикүк!" дип кычкырган тавыш ишетелә. Куян тавыштан куркып кача. Ә куян "Әни!", дип сөенеп тавышка йөгереп китә. Әтәчне күргәч, аптырый.

**Мияу:** Син кем?
**Әтәч:** Мин әтәч. Син кем?
**Мияу:** Мин песи. Мин Мияу.
Мияуга әтәчнең кикриге ошый.
**Мияу:** Бу нәрсә?
**Әтәч:** Кикрик.
**Мияу:** ***(сокланып)*** Матур.
Әтәч кукыраеп "Кикрикүк!" дип кычкырып җибәрә.
**Әтәч:** Мияу, син кая барасың?
**Мияу:** Өйгә. Мин кайта белмим ***(искә төшереп елап җибәрә).***
**Әтәч:** Мин Сертотмасны чакырыйм. Ул бар нәрсәне дә белә. Сертотмас, кил монда!
**Үрдәк:** Бак-бак! Хәерле көн!
**Мияу:** Хәерле көн! Син кем?
**Үрдәк:** Бак-бак! Мин үрдәк.
**Әтәч:** Син Мияуның өен белмисеңме? Ул адашкан.
**Үрдәк:** Бак-бак! Мин үрдәк. Мин бар нәрсәне беләм. Әйдә, киттек.

Әтәч белән Куян аларны озатып калалар. Үрдәк Мияуны өенә илтеп куя. Мияуның әнисе каршы чыга, Мияу белән кочаклашалар.

**Мияуның әнисе:** Үрдәк, зур рәхмәт сиңа!
**Мияу:** Рәхмәт сиңа! Әни мин сине яратам!
Алар икесе Үрдәкне кул болгап озатып калалар.

**2. Мультфильм ( 6 нчы шөгыль)"Аю баласы дөнья белән таныша."**
**<u>Персонажлар:</u>** Аю баласы, Аю-әни, малай, кыз, әти, әни.
**<u>Лексик доза:</u>** Бу кем? Нинди? Нишли? Сикерә, сикерәм, уйный, уйныйм, эчә, эчәм, йоклый, йоклыйм.
**<u>Күренеш:</u>** Матур җәйге урман. Кошлар сайрый, күбәләкләр оча. Зәңгәр күктә ак болытлар йөзә... Урман сукмагыннан баласын ияртеп Аю күренә.
**<u>Эчтәлек:</u>**
**Аю-әни:** Әйдә, акыллым, әйдә.

Аю баласы бар нәрсәне гаҗәпләнеп күзәтә, куркып тәпиләре белән битен томалый.

Бер аланда ялга чыккан гаиләне күрәләр. Әни аланда ашарга әзерли, әти сок эчә. Кыз скакалкада сикерә, малай туп уйный.

Аю баласы белән куаклар арасында аларны күзәтәләр. Кыз сикерә-сикерә алар янына ук килеп җитә яза. Аю баласы куркып әнисе артына кача. Кыз яңадан сикерә-сикерә әниләре янына юнәлә. Аю баласы әкрен генә Аю-әни артыннан чыга.

**Аю баласы:** Бу кем?

**Аю-әни:** Бу кыз.
**Аю баласы:** Кыз. Нинди кыз?
**Аю-әни:** Кечкенә, матур кыз.
**Аю баласы:** Кыз нишли?
**Аю-әни:** Кыз сикерә.
**Аю баласы:** Кыз сикерә. Мин дә сикерәм.

Аю баласы кыз кебек сикереп уйнап ала. Шул вакыт шап итеп алар янына гына туп килеп төшә. Аю баласы тагын куркып әнисе артына кача. Малай аларны күрми, йөгереп килеп тупны ала да, тупны икенче якка тибеп җибәрә һәм үзе дә туп артыннан йөгереп китә. Аю баласы әкрен генә Аю-әни артыннан чыга.

**Аю баласы:** Бу кем?
**Аю-әни:** Бу малай.
**Аю баласы:** Малай. Нинди малай?
**Аю-әни:** Зур, матур малай.
**Аю баласы:** Малай нишли?
**Аю-әни:** Малай уйный.
**Аю баласы:** Малай уйный?
**Аю-әни:** Әйе, малай уйный.

Аю баласы: “Малай уйный, мин уйныйм”, дип мәтәлчек атып уйный башлый. Аны әнисе тынычландыра: “Тс-с-с!”.

Инде аю-баласы төрлечә эти белән әнине күзәтә башлый. Әти сок эчә һәм “Тәмле!”, дип куя.

**Аю баласы:** Әни, бу кем?
**Аю-әни:** Бу эти.
**Аю баласы:** Әти? Әти нишли?
**Аю-әни:** Әти сок эчә.
**Аю баласы:** (көйсезләнеп) Минем дә сок эчәсем килә. Әни сок эчәм.
Аю-әни кесәсеннән сок чыгарып бирә.
**Аю-әни:** Мә сок.
**Аю баласы:** Рәхмәт.(Сикергәләп). Мин сок эчәм. Сок тәмле.

Әти, кыз, малай бергәләшеп куышып уйнап агачлар арасына кереп китәләр. Әни җыелмалы креслода күзләрен йомып, кояшка назланып утыра. Аю баласы аланга йөгереп чыга, аның да кинәт кенә эти, кыз, малай белән уйныйсы килеп китә.

**Аю-әни:** (пышылдап) Акыллым, кая барасың? Кил монда!
Аю  баласы әнине күреп аю-әни янына йөгереп килә дә, сорый.
**Аю баласы:** Бу кем?
**Аю-әни:** Бу әни.
**Аю баласы:** Әни матур, әйбәт. Әни нишли?
**Аю-әни:** Әни йоклый. Т-с-с-с!
**Аю баласы:** Әни йоклый?
Аю баласы авызын ачып исни башлый.
**Аю баласы:** Мин дә йоклыйм.

Әни аны кулына ала, тирбәтә-тирбәтә өенә кайтып китә.

Бишек җыры ишетелә.

**3. Мультфильм (9 нчы шөгыль) “Батыр Мияу һәм куркак Куянкай”**

**Персонажлар:** малай, Мияу, Куянкай.

**Лексик доза:** Бу нәрсә? Ул нишли? йоклыйм.

**Күренеш:** Куян кишер кимереп утыра, ә песи сөт эчкәннән соң үзен тәртипкә китереп, юынып утыра.

**Эчтәлек:**

**Малай:** Минем ак куяным һәм сары песием бар. Алар үзара бик дус яшиләр. Песи –бик батыр, бер нәрсәдән дә курыкмый, аның исеме Мияу. Ә куян – бик куркак, ул бөтен нәрсәдән курка, аның исеме Куянкай. Беркөнне кичкә таба шундый хәл булды.....

Куянкай бүлмәдә утыра. Шунда ул стенада үзенең шәүләсен күреп куркып кала.

**Куянкай:** *Бу нәрсә?* Ой, куркам... *Ул нишли?* Стенадан бара...Ой-ой, куркам. Хәзер *йоклый* да алмыйм инде.

Куянкай урынында куркып катып кала. Мияу йөгереп килә.

**Куянкай:** ***(тотлыгып)*** Мияу, кара әле (шәүләсенә күрсәтеп). *Бу нәрсә?* ***(кымшанганын күреп)*** *Ул нишли?*

**Мияу:** ***(аның үзенең шәүләсеннән курыкканын күреп көлеп җибәрә)*** Эх, син!! Куян! Куркак куянкай! Синең шәүләң бит ул. Бар, *йокла.*

Мияу кычкырып көлеп китеп бара. Куянкай тынычланып йокларга җыена. Аякларын юа.

**Куянкай:** ***(үз-үзенә көлемсерәп сөйләнә)*** *Бу нәрсә?* Бу мин. Уф! Үземнән үзем курыкканмын бит. Ярар, *йоклыйм.*

Шул вакыт кыштырдаган тавыш ишетелә, Куянкай тагын шомланып тынып кала.

**Куянкай:** *Бу нәрсә?* Ой, куркам... *Ул нишли?* Ой-ой, куркам. Хәзер *йоклый* да алмыйм инде.

Мияу килеп, колакларын торгызып шомраеп кала.

**Куянкай:** Мияу, *бу нәрсә? Ул нишли*? Мияу, син дә куркасыңмы?

Мияу кинәт сикерә һәм әсирлеккә (пленга) алган кебек тычканны өстәл астыннан тартып ала. Тычкан башын аска иеп тора.

**Мияу:** Куянкай, менә сине кем куркыткан.

**Куянкай:** Тычкан. Тычкан кечкенә, матур. Нишләп шулай тавышланып йөрисең? Куркыттың бит.

**Мияу:** Менә хәзер тынычлап йоклыйк инде. Куянкай, *йокла.* Тычкан *йокла.* Хәерле төн, Куянкай! Хәерле төн, Тычкан! Шаулашып йөрмә башка!

**Тычкан:** Ярар. Рәхмәт! Хәерле төн!

**Куянкай:** Хәерле төн!

**Малай:** Менә шундый батыр минем Мияукаем.

**4. Мультфильм (12 нче шөгыль) “Тату гаилә”**

**Персонажлар:** Бабай, әби, әни, Азат исемле малай, Алсу исемле кыз. Кәҗә, песи, эт, әтәч, тавыклар.
**Лексик доза**: Нишлисең? Ашыйм, эчәм, уйныйм.
**Күренеш:**
Ишек алды күренеше. (Өй тәрәзәсе ачык. Әби белән бабай өстәл артында сөйләшә - сөйләшә ашап – эчеп утыралар. Баскычта Мияу кояш нурлары астында җылынып ята, Акбай оясы янында матур татар халык көенә өреп җырлап утыра. Азат белән Алсу комлыкта уйныйлар. Әтәч үзенең тавыклары белән җим чүпли. Кәҗә бакчага кергән, як – ягына карана- карана кәбестә ашый.
**Эчтәлек:**
Капкадан сумкаларын күтәреп әни кайтып керә. Азат белән Алсу әниләрен күрәләр, йөгереп килеп кочаклап алалар.
**Азат белән Алсу:** Урра – урра, әни, әни!
Әни штланып, балаларын кочаклап, аркаларыннан сөя, балалары белән сөйләшә.
**Әни:** Азат, нишлисең?
**Азат:** Мин машина белән уйныйм *(машинасын күрсәтә).*
**Әни:** Алсу, син нишлисең?
**Алсу:** Мин туп белән уйныйм *(тупны күрсәтә)*. Әни, кара, мин сикерәм *(сикереп күрсәтә)*.
**Әни балаларның башларннан сыйпый, мактый:**
- Азат, син зур, матур малай.
- Алсу, син зур, матур малай.
- Азат, бар, уйна!
- Алсу, бар, уйна! (балалар йөгереп уйнарга китәләр)
**Әни баскычта яткан песин күреп ала:** Песи, нишлисең?
**Мияу:** Мияу – мияу! Мин сөт эчәм. Сөт тәмле. Мин сөт яратам.
**Әни җырлап утырган эткә көлеп карап тора, сорый:** Акбай, Акбай, син нишлисең?
**Акбай:** һау – һау – һау! Мин җырлыйм *(татар көенә җырлый)*
Һау – һау – һау!
Һа – у, һа – у, һа – у!
У – у – у!
**Әни өйгә керә:**
- Хәерле көн, әби!
- Хәерле көн, бабай!
- Хәлләр ничек?
**Әби, бабай:** Рәхмәт, әйбәт.
**Әни:** Әби, син нишлисең?
**Әби:** Мин чәй эчәм.
**Әни:** Бабай, син нишлисең?
**Бабай:** Мин аш ашыйм. Әйдә, син дә утыр.
**Әби:** Чәй эч! Аш аша!
Әни өстәл артына утыра, рәхмәт әйтә.
Өчәүләп тәмләп сыйланалар. Шул вакыт тәрәзәдән бакчага кергән кәҗәне күреп шаккаталар.

**Бабай ачуланып кычкыра:** Кәҗә, син нишлсең?
**Кәҗә:** Ме – ме – ме! Мин кәбестә ашыйм. Кәбестә тәмле. Мин кәбестә яратам.
**Бабай:** Әй, кәҗә, кәҗә! Ярамый, чык. Кил монда. Мин сиңа печән бирәм, су бирәм.
Бабай кәҗәне сыйлый. Кәҗә рәхмәт әйтә, сакалын селкетә.

**5. Мультфильм (15 нче шөгыль) "Юмарт аю"**
<u>**Персонажлар:**</u> Аю, куян, керпе, төлке, бүре.
<u>**Лексик доза**:</u> Нишлисең? Ашыйм.
<u>**Күренеш:**</u> Урманнан ерак түгел көмеш сулы елга янында Аюның яшелчә бакчасы. Ул анда яшелчәләр үстерә.
<u>**Эчтәлек:**</u>
Яшел куе урманда бер бик матур алан булган. Бу аланда Аю яшәгән. Ул бик эшчән, тырыш булган. Язлар җитеп карлар эреп беткәч, ул җирне казып түтәлләр ясаган, кишер, кәбестә утырткан. Җәен дә тик тормаган, яшелчәләрне караган, сулар сипкән, төпләрен йомшарткан, чүп үләннәрен утаган. Аю яшелчәләрне барлап йөри.
**Аю:** (кишер түтәле янында йөри) Бу нәрсә?
Җирдән бер **суалчан** башын күтәргән дә: Бу кишер, - дип җавап биргән.
Аю кәбестә түтәле янына килеп аларны да караган.
**Очып йөрүче күбәләкләр:** Бу кәбестә, зур кәбестә, дип пышылдаганнар.
**Аю:** әйе, кәбестә. Кәбестә зур, - ди.
Суган түтәле өсеннән камка тутый очып үтә, кире борылып аюның җилкәсенә килеп куна.
**Камка тутый:** Бу нәрсә:
**Аю:** Бу суган. Суган файдалы, - ди.
Бәрәңге түтәле янына үзенең оясыннан башынтыгып бер тычканкарап тора.
**Тычкан:** Бәрәңге. Бә-рәң-ге!
**Кошлар** да аюның бакчасына игътибар итмичә калмыйлар, помидор, кыярларны күреп шак каталар: Помидор кызыл, кыяр яшел, - диләр.
Менә матур көз дә килеп җиткән. Аю мул уңыш җыеп алган. Яшелчәләрне зур капчыкка төяп елга уена киткән. Яшелчәләрне юган, аларны киптереп капчыкка тутырган. Ул арыган.
**Аю маңгай тирләрен сөртеп:** Уф, арыдым. Яр буена утырып бераз ял итеп алыйм әле.
Капчыктан бер кишерне алып ашый башлаган. Шул вакыт урманнан куян сикереп килеп чыга.
**Куян:** Исәнме, Аю.
**Аю:** Исәнме, Куян.
**Куян:** Хәлләр ничек?
**Аю:** Әйбәт, Куян дус. Рәхмәт. Куян, син нишлисең?
**Куян:** Мин сикерәм (сикереп күрсәтә). Ә син нишлисең?
**Аю:** Кырр ашыйм. Кыяр тәмле. Мә, кыяр, аша.

**Куян:** Юк. Мин кишер яратам.
**Аю:** Куян, мә кишер, аша. *(Аю куянга капчыктан кишер алып бирә).*
**Куян:** Рәхмәт. Мин кишер яратам. Кишер тәмле. Кишер баллы.

Аю белән куян кишер ашап утырган вакытта урманнан көлешә - көлешә төлке, керпе, бүре килеп чыгалар. Аю белән куянны күреп алар янына киләләр.

**Төлке:** Куян, син нишлисең?
**Куян:** Кишер ашыйм. Кишер тәмле. Кишер баллы.
**Төлке:** Аю, син нишлисең?
**Аю:** Кыяр ашыйм. Мә, кыяр аша
**Төлке:** Рәхмәт. Кыяр исенә тычкан йөгереп килә.
**Тычкан:** Пи-пи-пи. Мин сыр яратам.
**Төлке:** Сыр юк, мә кыяр аша.
**Тычкан (**кыярны кимереп карый): Ай-яй тәмле! Рәхмәт, аю! Рәхмәт, төлке!
**Аю:** Керпе, мә кишер аша *(кишер бирә).*

**Төлке белән бүрене чакыра, аларны да кишер, кыяр, помидор белән сыйлый. Аюга барлык җәнлекләр рәхмәт әйтәләр, мактыйлар**

Ашап бетерәләр дә кулга – кул тотынышы түгәрәккә басып җырлый – җырлый бииләр.

Бар минем зур бакча,
Кишер, кәбестә үсә.
Кыяр, бәрәңге үсә,
Помидор, суган үсә.

Кишер кишер, тәмле кишер.
Кыяр, кыяр, тәмле кыяр.
Әйе шул, әйе шул.
Тәмле кишер, тәмле кыяр.

Кишер, кишер, баллы кишер.
Кыяр, кыяр, тәмле кыяр.
Әйе шул, әйе шул.
Баллы кишер, тәмле кыяр.

**6. Мультфильм (18 шөгыль) “Кафега барабыз.”**

**<u>Персонажлар:</u>** Мияу, Акбай, аю, куян, керпе, тычкан. Төлке официант ролендә.

**<u>Лексик доза</u>**: Барам. Кая барасың? Син нишлисең?

**<u>Күренеш:</u>** Җәйге матур кояшлы көн. Шәһәр урамы, йортлар, кибетләр, кафелар, балалар бакчасы күренешләре.

**<u>Эчтәлек:</u>** Урамда Акбай белән Мияу очрашалар, матур киенгәннәр. Акбай аркасына рюкзак аскан. Мияуның беләгендә сумка, муенына фотоаппарат аскан.

**Акбай:** Исәнме, Мияу!

**Мияу:** Исәнме, Акбай! Хәерле көн!
**Акбай:** Мияу, хәлләр ничек?
**Мияу:** Әйбәт, рәхмәт. Акбай, кая барасың?
**Акбай:** Мин кафега барам. Мияу, ә син кая барасың?
**Мияу:** Мин дә кафега барам. Әйдә киттек.
*Икәү бергә "Тәмле" кафесына китәләр, керәләр. Кафеда зур өстәл артында бүре, аю, кечкенә өстәл артында куян, керпе, тычкан ашап, эчеп утыралар. Төлке официант. Акбай белән Мияу кул болгап: "Сәлам, дуслар!" – дип исәнләшәләр. Тычкан песидән шүрләп керпе артына яшеренә.*
**Мияу көлеп:** Качма, качма, тычкан. Кил, утыр, матур утыр!
*Тычкан чыгып, матур итеп утыра.*
**Мияу:** Тычкан, хәлләр ничек?
**Тычкан:** Рәхмәт, әйбәт.
**Мияу:** Син нишлисең?
**Тычкан:** Ипи ашыйм, сөт эчәм. Сөт тәмле! Әйдә, Мияу, утыр, аша, эч!
**Мияу:** Рәхмәт, рәхмәт, тычкан. Акбай, әйдә, син дә утыр! (бергәләшеп утыралар)
**Төлке:** Хәерле көн, Мияу! Хәерле көн, Акбай! Мияу, сиңа нәрсә кирәк?
**Мияу:** Коктейль кирәк. Чәк-чәк кирәк.
**Тцлке:** Акбай, сиңа нәрсә кирәк?
**Акбай:** Миңа өчпочмак кирәк. Сок кирәк.
**Төлке:** Бер минут көт! Яңадан әйләнеп килә, подноста Акбай белән Мияу сораган ашамлыклар.
**Төлке:** Мияу, мә, коктейль эч. Чәк-чәк аша!
**Мияу:** Рәхмәт, төлке.
**Төлке**: Акбай, мә сиңа өчпочмак, аша! Менә сок, эч!
**Акбай:** Рәхмәт, төлке.
*Барысы да ашыйлар, эчәләр, үз-ара сөйләшәләр.*
**Мияу:** Чәк-чәк баллы. Акбай, өпочмак тәмле?
**Акбай:** Әйе, тәмле. Синең коктейль баллы?
**Мияу:** Баллы.
*Акбай борылып бүре белән сөйләшә.*
**Акбай:** Бүре,син нишлисең?
**Бүре:** Мин пицца ашыйм. Син нишлисең?
**Акбай:** Мин өчпочмак ашыйм.
**Бүре:** Нәрсә?
**Акбай:** Өч – поч – мак. Өчпочмак тәмле.
**Мияу:** Керпе, син нишлисең?
**Керпе:** Мин алма ашыйм. Мин алма яратам. Алма баллы.
**Мияу:** Мин коктейль эчәм. Коктейль тәмле.
*Музыка уйнап тора, шулай сөйләшә-сөйләшә җәнлекләр сыйланалар.*

**7. Мультфильм (21 нче шөгыль) "Урманда күңелле уеннар."**
**Персонажлар:** Шүрәле, Урман кызы. Куян, керпе, төлке, бүре, аю.

**Лексик доза:** Сикер – сикерәм. Бие – биим.

**Күренеш:**

Урман күренеше. Төрле агачлар, матур чәчәкәр үсеп утырган хуш исле алан. Чәчәкләр өстеннән күбәләкләр очкалый. Карт имән тирәли түгәрәк ясап урман җәнлекләре: куян, керпе, төлке, бүре, аю төзелешеп утырганнар. Күңелсезләр.

**Эчтәлек:**

Агачлар арасыннан, аркасына тальян гармун асып, Шүрәле килеп чыга, күңелсезләнеп утырган җәнлекләрне күреп гаҗәпләнеп карап тора.

**Шүрәле:** Исәнмесез, дуслар! Хәерле көн! *(Җәнлекләр теләр – теләмәс кенә исәнләшәләр)*

**Шүрәле:** Нәрсә булды? Нигә сез күңелсез?

**Аю:** Әй, Шүрәле! Безгә күңелсез, минем уйныйсым килә.

**Куян:** Минем сикерәсем килә.

**Төлке:** Минем җырлыйсым килә.

**Бүре:** Ә минем йөгерәсем килә.

**Шүрәле:** Юк, юк, дуслар! Күңелсезләнеп тормагыз. Әйдәгез, бергә күңел ачабыз, уйныйбыз, җырлыйбыз, биибез. Килегез, түгәрәккә басыгыз!

Шүрәле гармунын уйнап җибәрә. Команда биреп тора, җәнлекләр түгәрәктә төрле хәрәкәтләр ясыйлар.

- Марш! Бер – ике, бер – ике.
- Бас, утыр! Бас, утыр! (чүгәлиләр, торып басалар)
- Сикер! (сикерәләр)
- Йөгер! (йөгерәләр)

**Шүрәле:** Минем матур туп бар! Әйдәгез, уйныбыз. *(Җәнлекләрне ике командага бүлеп бастыра)*

- Куян, кил монда!
- Керпе, кил монда!
- Төлке, кил монда!
- Бүре, кил монда!
- Аю, кил монда!

Шүрәле команда биреп тора, җәнлекләр тупны тотып йөгерәләр, агачны әйләнеп киләләр дә тупны иптәшләренә бирәләр.

**Шүрәле:**

1 – 2 – 3! Куян сикер!

**Куян:** Мин сикерәм!

**Куян сикереп – сикереп агачны әйләнеп килә дә, тупны керпегә бирә:**

1 – 2 – 3! Керпе, сикер!

**Керпе:** Мин сикерәм !

**Керпе сикереп – сикереп агачны әйләнеп килә дә, тупны төлкегә бирә:**

1 – 2 – 3! Төлке, сикер!

**Төлке:** Мин сикерәм!

**Төлке сикереп – сикереп агачны әйләнеп килә дә, тупны бүрегә бирә:**

**Шүрәле:** 1 – 2 – 3! Бүре, йөгер!

**Бүре:** Мин йөгерәм!

**Бүре йөгерә - йөгерә агачны әйләнеп килә, тупны аюга бирә:**
1 – 2 – 3! Аю, йөгер!
**Аю:** Мин йөгерәм.
Барлык җәнлекләр дә шатланалар, Шүрәле аларны мактый.
Шүрәле гармунын уйнап җибәрә. Шул вакыт агачлар арысыннан милли кием кигән Урман кызы чыга.
**Урман кызы:** Исәнмесез, дусларым!
**Шүрәле һәм җәнлекләр:** Исәнме, Урман кызы.
**Урман кызы:** Шүрәле, син нишлисең?
**Шүрәле:** Уйныйм. (гармунда уйный)
**Урман кызы:** Нинди матур бию көе! Әйдәгез, дуслар, биибез.
- Куян, кил, бие!
- Керпе, кил, син дә бие!
- Төлке, кил, бие!
- Бүре, кил, син дә бие!
- Аю, әйдә, кил биибез!
Урман кызы, Шүрәле, барлык җәнлекләр бергә җырлап бииләр.

**8. Мультфильм (24 нче шөгыль) "Көчлеләр, кыюлар, җитезләр."**
**Персонажлар:** Тычкан, бүре, куян, Мияу, Акбай.
**Лексик доза:** Сикер, сикерәм, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак.
**Күренеш:** Таң ата, әтәч кычкыра. Акбай белән Мияу 1дән-10га кадәр санап, иртәнге гимнастика ясыйлар.
**Эчтәлек:**
**Акбай сикерә, Мияуга әйтә:** Мияу сикер. Мияу нишлисең?
**Мияу:** Мин сикерәм. (Мияу сикерә, Акбайга әйтә) Акбай, йөгер. Акбай нишлисең?
**Акбай:** Мин йөгерәм.
Акбай белән Мияу тычканны, бүрене, куянны чакыралар:
- Тычкан (бүре, куян) кил монда.
Казанга, спорт бәйрәменә барырга җыенулары турында сөйлиләр.
**Акбай:** Мин Казанга барам. Спорт бәйрәмендә йөгерәм, сикерәм.
**Тычкан:** Мин дә Казанга барам.
**Акбай:** Юк, син кечкенә. Син уйна.
**Тычкан:** Юк, мин әйбәт йөгерәм, Казанга барам, барам.
**Куян:** Мин зур, әйбәт сикерәм. Мин Казанга барам.
**Бүре:** Мин әйбәт сикерәм, йөгерәм. Мин Казанга барам.
Мияу белән Акбай барлык хайваннарны да үзләре белән бергә Казанга, ярышка барырга чакыралар.
Кассадан билет сорап алалар:
- Билет бир әле.
- Син кая барасың?
- Казанга барам.
- Мә, билет. Утыр.
- Рәхмәт.

Ял итү урынында туктап чәк-чәк, өчпочмак ашыйлар.
- Исәнмесез.
- Миңа өчпочмак (чәк-чәк) кирәк.
- Мә, өчпочмак (чәк-чәк).
- Рәхмәт. (Ашыйлар)
- Өчпочмак (чәк-чәк) тәмле.
- Мин өчпочмак (чәк-чәк) яратам.

Поездга утырып, җырлап баралар:
Мин барам, барам, барам.
Казанга барам, барам.
Әйе шул, әйе шул,
Казанга барам, барам.

**9. Мультфильм (27 нче шөгыль) “Җәнлекләр спорт бәйрәмендә.”**

**Персонажлар:** Эт Акбай, песи Мияу, аю, бүре, төлке, куян, керпе, тычкан.
**Лексик доза:** Сиңа ничә яшь?, бүре, керпе.
**Күренеш:** Стадион. Акбай, Мияу, аю, бүре, төлке, куян, керпе, тычкан спорт бәйрәменә килгәннәр. Барысы да спорт киеменнән. Алар каршына корреспондент килә.
**Эчтәлек:**
**Корреспондент:** Исәнмесез. Мин корреспондент, син кем?
**Бүре:** Мин бүре. Мин зур, матур, чиста, әйбәт бүре.
**Корреспондент:** Сиңа ничә яшь?
**Бүре:** Алты яшь.
**Корреспондент:** Бүген син нишлисең?
**Бүре:** Мин йөгерәм, сикерәм.
**Корреспондент:** Рәхмәт. Ә син кем?
**Керпе:** Мин керпе. Мин кечкенә, матур керпе.
**Корреспондент:** Сиңа ничә яшь?
**Керпе:** Биш яшь.
**Корреспондент:** Син нишлисең?
**Керпе:** Мин сикерәм, йөгерәм.
**Корреспондент:** Рәхмәт. Уңышлар сезгә! Удачи вам!
Корреспондент китә.
**Радиодан диктор тавышы:** Соревнования начинаются! Ярышлар башлана!
**Акбай:** Мин-тренер. Аю, төлке, тычкан – минем команда. (Кил монда).
**Мияу:** Мин-тренер. Бүре, куян, керпе – минем команда. (Кил монда).
Җәнлекләр Акбай һәм Мияу командасына бүленеп, алар янына төзелеп басалар.
**Диктор:** 1-нче ярыш: “Йөгер!”
Һәр командага туп бирелә. Акбай тупны аюга бирә һәм әйтә:
- Аю, мә туп, йөгер!

Аю тупны тотып билгеләнгән урыннан йөгереп килеп, тупны тычканга бирә һәм әйтә:

- Тычкан, мә туп, йөгер!

Мияу командасы да шулай ук йөгереп килеп тупны бер-берсенә бирәләр:

- Бүре, мә туп, йөгер!
- Куян, мә туп, йөгер!
- Керпе, мә туп, йөгер!

Акбай командасы беренче килә, алар җиңүче. Җәнлекләр шатланалар, бер-берсен кочаклыйлар.

**Диктор:** 2-нче ярыш: “Сикер!”

Башта Мияу командасы еракка сикерә.

**Җәнлекләр:**

- Бүре – сикер!
- Куян – сикер!
- Керпе – сикер! – дип кычкырып торалар.

Акбай командасы сикерә.

- Аю – сикер!
- Төлке – сикер!
- Тычкан – сикер!

Бу юлы Мияу командасы җиңде. Хәзер алар шатланып, кочаклашалар.

**Диктор:** Акбай командасы – 1 очко. Әйбәт.

Мияу команасы – 1 очко. Әйбәт.

- Молодцы! Вам подарки. Сезгә бүләкләр.

Һәрберсенә бүләккә чәк-чәк таратыла.

**Җәнлекләр барысы бергә:** Рәхмәт. Чәк-чәк тәмле, - диләр.

**10 Мультфильм (30 нчы шөгыль) “Циркта.”**

**Персонажлар:** тавык, әтәч, үрдәк, Мияу, Акбай, бүре.

**Лексик доза:** тавык, әтәч, үрдәк.

**Күренеш:**

Авыл иртәсе. Ишек алды. Әтәч коймага очып менә дә “Кикрикүк” дип кычкыра. Шунда җим чүпләп йөргән тавыкка: “Хәерле иртә, тавык”, ди.

**Эчтәлек:**

**Тавык:** Кык-кыт. Хәерле иртә, әтәч.

**Әтәч:** Хәлләр ничек, тавык?

**Тавык:** Әйбәт.

**Әтәч:** Нишлисең?

**Тавык:** Ипи ашыйм.

Шунда әтәч үрдәкне күреп ала.

- Кикрикүк, хәерле иртә, үрдәк.
- Бак-бак, хәерле иртә, әтәч.
- Үрдәк, нишлисең?
- Су эчәм.

Әтәч яныннан Акбай үтеп бара:

- Кикри-күк, Акбай, кая барасың?
- Мин циркка барам.

Акбай өй ишеген шакый:

- Мияу, әйдә циркка.
- Әйдә.

Мияу өйдән чыга, алар икәүләп циркка китәләр.
Алар “Цирк” дип язылган бинага керәләр.
**Мияу:** Цирк матур, зур.
Җәнлекләрнең читлекләре янына киләләр.
**Мияу *(куркып):*** Акбай, бу-бу-бу ке-е-ем? Нинди зу-у-ур.
**Акбай:** Бу аю, куркма, бу аю әйбәт.
**Мияу:** Ә-ә-ә. Ә бу кем? Нинди матур.
**Акбай:** Бу төлке. Төлке йоклый. Тс-с.
Мияу (шыпырт кына): Ә бу кем? Ай-яй-яй, усал.
**Акбай:** Бу бүре, бүре дә әйбәт.
- Исәнме, бүре.

**Бүре:** Исәнме, Акбай. Хәлләр ничек?
**Акбай:** Әйбәт. Циркта нишлисең?
**Бүре:** Сикерәм, утырам, уйныйм.
**Мияу:** Ә бу тычкан. Мин беләм. Тычкан кечкенә, матур. Тәмле-е-е, ашыйм, мя-я-яу.
**Акбай:** Юк, юк, ашарга ярамый, әйдә киттек.
Залга керәләр.
**Акбай:** Мияу, кил монда, утыр.
**Мияу:** Рәхмәт, Акбай. Мин цирк яратам.
**Акбай:** Мин дә цирк яратам.

**11. Мультфильм (33 нче шөгыль)“Шаян кошлар”**
**<u>Персонажлар:</u>** Әтәч, тавык, үрдәк.
**<u>Лексик доза:</u>** Әтәч, тавык, үрдәк, чана, шуам, шуа.
**<u>Күренеш:</u>** Кышкы ишек алды күренеше. Кар яуган. Өйләр, сарайлар, эт оясы түбәсендә, коймаларда кар яткан.
Сарайның ишеге ачылып китә, кышкы киемнән киенгән әтәч, тавык һәм үрдәк чыгалар. Карны күреп куяннар, карда ятып ауныйлар, кар атышып уйныйлар.
**<u>Эчтәлек:</u>**
Әтәч, сикереп, коймага менә дә:
Кикри-күк. Хәерле көн.
Мин әтәч. Кикри-күк.
Мин матур әтәч, дип кычкыра.
Үрдәк, әтәчтән үчекләп көлә. Кикерик-кикри-күк, дип, тәгәрәп килеп төпкә баса, коймага терәп куелган баскыч буенча үрмәли-үрмәли коймага менә:
- -- Бак-бак-бак. Хәерле көн, мин үрдәк. Мин матур үрдәк, дип кычкыра-кычкыра мәтәлеп төшә, торып утыра, бак-бак, “мин утырам”, -ди.
Әтәч белән тавык үрдәктән көләләр. Янына килеп, үрдәкнең өстен кагалар, киемнәрен рәтлиләр.
Тавык баскычның иң аскы баскычына сикереп баса: Ко-ко-ко.
- Мин тавык, мин тавык,

Мин бик матур тавык.
Мин җырлыйм ко-ко-ко,
Мин биим тып-тып-тып.
Әйе шул, әйе шул,
Мин бик матур тавык.

Әтәч тавыкны күтәреп төшерә, кар атып уйныйлар. Үрдәк аларга кушыла, шул вакыт өйгә терәп куйган чанага күзләре төшә.

**Әтәч:** Бу нәрсә?
**Тавык:** Белмим.
**Үрдәк:** Бел. Бу чана.
**Тавык, әтәч:** Чана?
**Үрдәк:** Чана. Зур чана. Матур чана. Мин чана шуам.
Чананы алып утыра.
**Үрдәк:** Мин чана шуам.
**Әтәч (тавыктан сорый):** Үрдәк нишли?
**Тавык:** Чана шуа.
Өчәүләп җырлап, чана шуалар.

- Мин әтәч, чана шуам.
- Мин тавык, чана шуам.
- Мин үрдәк, чана шуам.

Чана шуып туйгач, чананы урынга терәп куялар да, рәхмәт әйтеп, саубуллашалар.

**12. Мультфильм (36 нчы шөгыль) "Урманда зур концерт."**
<u>**Персонажлар:**</u> куян, аю, төлке, керпе, тычкан, бүре.
<u>**Лексик доза:**</u> бие, бии, биим.
<u>**Күренеш:**</u> Җәйге урман өстеннән саескан очып хәбәр бирә: Концерт! Концерт! Зур аланда концерт! Килегез дуслар!
Урман аланында сәхнә күренеше. Буш утыргычларга җәнлекләр җыелып утыра башлый. Үзара сөйләшәләр.
<u>**Эчтәлек:**</u>
Гаиләсе белән аю килеп утыра. Балалары белән куян килә.
**Куян:** Исәнме, аю.
**Аю:** Исәнме, куян. Хәлләр ничек?
**Куян:** Әйбәт, рәхмәт *(Куян балалары шаяралар, әни куян аларны тәртипкә сала).*

- Утыр, матур утыр, - ди.

**Гаиләсе белән төлке килә:** Исәнмесез дуслар, хәерле көн *(Утыралар).*
**Керпе килә:** Исәнмесез дуслар, хәерле көн.
**Тычкан килә:** Исәнмесез дуслар, хәерле көн.
Җәнлекләр җыелып беткәч, музыка уйный, тынлык урнаша. Концерт костюмыннан киенгән алып баручы төлке һәм бүре чыгалар.
**Бүре:** Хәерле көн, дуслар.
**Төлке:** Исәнмесез, концертны башлыйбыз. Куян бии! Керпе гармунда уйный!

Куян чыга, музыка астында бии, баш иеп кереп китә. Җәнлекләр гөрләп кул чабалар. Бер бүре торып сызгыра:

- Куян тагын бие! Куян, куян, куян! Бие! Бие! Бие! – дип кычкыра.

Куян яңадан чыга:

- Мин биим, - ди.

Яңадан бии. Кул чабып озаталар.

Алып баручылар чыга.

**Бүре:** Аю җырлый!

**Аю:** Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Әйе шул, әйе шул,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.

Кул чабалар, аюдан яңадан җырлавын сорыйлар:

- Аю җырла! Аю җырла!

Аю чыга, баш ия, рәхмәт әйтә.

**Аю:** Ярар, ярар, җырлыйм.
Мин биим, биим, биим,
Мин матур биим, биим.
Мин биим, биим, биим,
Мин матур биим, биим.
Әйе шул, әйе шул,
Мин матур биим, биим.

Алып баручылар чыгалар.

**Бүре, Төлке:** Керпе шигырь укый.

Керпе туп күтәреп чыга.

**Керпе:** "Матур туп"
Туп, туп, матур туп,
Сикер, сикер, матур туп.
Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Сикер, сикер матур туп.

*(Туп сикертеп, уйнап сөйли).*

Җәнлекләр кул чабалар, рәхмәт әйтәләр.

Алып баручылар чыгалар.

**Төлке:** Куяннар-акробатлар уйный!

*(Куяннар төрле акробатик күнегүләр ясап уйныйлар).*

Җәнлекләр кул чабалар, рәхмәт әйтәләр.

Алып баручылар чыгып:

- Ә хәзер без биибез. Музыка, уйна!

*(Матур татар көе уйный, җәнлекләр утыргычларны кырыйга җыеп куялар, уртага чыгып, бергәләп бииләр).*

**13. Мультфильм (39 нчы шөгыль) “Акбай туган көнгә барырга әзерләнә.”**

**Персонажлар:** Акбай, Сатучы.

**Лексик доза:** күлмәк, чалбар, ак, кара.

**Күренеш:** Акбай кибеткә килгән.

**Эчтәлек:**

**Акбай:** Исәнмесез.

**Сатучы:** Исәнмесез. Нәрсә кирәк?

**Акбай:** Мин туган көнгә барам. Миңа матур күлмәк, чалбар кирәк.

**Сатучы:** Ак күлмәк, кара чалбар бар.

**Акбай:** Мин ак күлмәк яратам.

**Сатучы:** Мә, ак күлмәк.

**Акбай:** Ак күлмәк матур, рәхмәт. Кара чалбар да бирегез әле.

**Сатучы:** Мә, кара чалбар.

**Акбай:** Рәхмәт. Сау булыгыз.

**Сатучы:** Сау булыгыз.

Акбай өенә кайта. Күлмәкне, чалбарны көзге каршында киеп карый, җырлый, бии:

1)Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Әйе шул, әйе шул,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
2)Мин биим, биим, биим,
Мин матур биим, биим.
Мин биим, биим, биим,
Мин матур биим, биим.
Әйе шул, әйе шул,
Мин матур биим, биим.

Җырлап туктагач телефоннан шалтырата:

- Алло. Бу цирк? Миңа төлке кирәк. Ә бу төлкеме? Исәнме төлке. Мин Акбай. Хәлләр ничек? Нишлисең? Мияуның туган көненә барасыңмы? Мин барам. Минем ак, матур күлмәгем, кара чалбарым бар. Әйдә кил, бергә туган көнгә барабыз, җырларбыз, биербез. Сау бул, төлке, - дип трубканы куя да яңадан:
- Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм, - дип җырлый.

**14. Мультфильм (42 нче шөгыль) “Мияуның туган көне.”**

**Персонажлар:** Мияу, Акбай, этәч, тавык, үрдәк, тычкан.

**Лексик доза:** зур рәхмәт, җырлыйбыз.

Мияу бәйрәмчә киенгән. Аның бүген туган көне. Алдына альяпкыч япкан да җырлый-җырлый бәйрәм табыны әзерли. Өстәлдә пар чыгарып самавыр утыра. Табында чәк-чәк,өчпочмак, алма, виноград, торт, салат.

Савыт-сабалар ялт-йолт итеп торалар, үзара нидер сөйләшәләр. Талгын гына музыка ишетелеп тора.

**Күренеш:** Ишек алды. Әтәч коймада, тавык җим эзләп йөри, үрдәк тагарактан су эчә, тычкан оясыннан чыккан, баскыч янында ипи кимереп утыра.

Бәйрәмчә киенеп оясы янында Акбай тора. Ак күлмәк, кара чалбар кигән. Кесәсеннән көзге алып, өс-башларын төзәтә. Оясыннан түбәтәен алып кия дә, кулына чәчәк бәйләме һәм торт тотып дусты Мияуның туган көненә барырга җыена. Әтәч койма башыннан Акбайны күзәтеп тора да: Кикрикүк!-дип кычкыра.

**Эчтәлек:**

**Акбай:** Һау – һау – һау! (куркып як –ягына карана). Нәрсә бар? Кем бу?

**Әтәч:** Кикрикук! Кикрикүк! Акбай, кая барасың иртүк?

**Акбай:** Син икән әтәч. Туган көнгә барам. Бүген минем дустым Мияның туган көне. Мияуга алты яшь. Әйдә, әтәч! (әтәчне чакыра)

**Әтәч:** Кикрикүк! Кикрикүк! Тавык, тавык, кил монда.(тавык йөгереп килә).

**Тавык:** Ко –ко –ко! Нәрә бар?

**Әтәч:** Мияуга алты яшь. Әйдә, туган көнгә барабыз.

**Тавык:** Кыт – кыт – кыт! Кет – кет – кет! Көт – көт – көт, 1 минут көт!(йөгереп көтәккә кенеп китә. Ике йомырка яткан оясының саламын актарып, кәрзингә киндер-сюрпризләр тутыра да яңадан йөгереп чыгып әтәч янына килә:

- Әйдә, киттек. (Өчәүләп – Акбай, әтәч, тавык китәләр).

Ләгәннән су эчеп торган үрдәкне күреп алалар.

**Бергә:** Үрдәк дус, ни хәлләр? Әйдә туган көнгә, Мияуга алты яшь.

**Үрдәк:** Бак – бак – бак! Бак – бак – бак! Барам, барам. (тиз генә чәчәк түтәленә килеп, томшыгы белән бер чәчәк өзеп ала. Матурлана. Алпан – тилпән атлап иптәшләрен куып тота.

Акбай, әтәч, тавык, үрдәк Мияуның өенә килеп җитәләр. Баскыч янында ипи кимереп утырган тычканны күреп исәнләшәләр

**Бергә:** Исәнме, тычкан. Хәлләр ничек?

**Әтәч:** Тычкан, нишлисең?

**Тычкан:** Ипи ашым. Ипи тәмле. Мә, ипи аша!

**Әтәч:** Зур рәхмәт. Мин туган көнгә барам.

**Акбай:** Әйдә Мияуга.

**Тычкан:** Мияуга!! Юююк – ююкк! Бармыйм. (як-ягына карана). Мин куркам ( чыелдый-чыелдый баскыч астына кереп кача). Пи – пи – пи! Чи – чи – чи!

Тычкан чыелдаган тавышны ишетеп өйдән Мияу чыга. Дусларын күреп шатлана.

Мияу дусларын каршы ала.

**Акбай, әтәч, тавык, үрдәк:** Исәнме, Мияу. Туган көнең белән! (бүләкләрен бирәләр)

**Акбай:** Туган көнең белән, Мияу. Менә сиңа бүләк (чәчәк бәйләмен һәм торт бирә)
**Мияу:** Зур рәхмәт, Акбай.
Әтәч, тавык Мияу каршына чыгалар.
**Тавык:** Мә, ал (киндер-сюрпризлар салынган кәрзин бирә)
**Мияу:** (кәрзинне ала) Нәрсә бу?
**Тавык:** Сюрприз!
**Әтәч:** Әйдәгез, җырлыйбыз. (бергә җырлыйлар).

Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
Әйе шул, әйе шул,
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.

**Үрдәк:** Туган көнең белән, Мияу. (чәчәк бирә)
**Мияу:** Рәхмәт, үрдәк. Әйдә, керегез! (дусларын өйгә чакыра)
Барысы да өйгә керәләр. Мияу дусларын сыйлый. Соңыннан барысы да бергә Мияуга җыр җырлыйлар. Иптәшләре түгәрәк ясап басалар. Мияу уртада.

**15. Мультфильм (45 нче шөгыль) "Урман китапханәсендә."**
**Персонажлар:** Әни аю, аю баласы, куян, бүре, төлке, керпе.
**Лексик доза:** Китап, укый, рәсем ясый.
**Күренеш:** Урман аланында бик матур өй тора. Башына "Китап" дип язылып куелган. Ишегеннән китап кыстырып җнлекләр кереп китәләр: китаплары төрле-төрле төстә, төрл зурлыкта. Аю баласы әнисе белән китаплар өенә киләләр.
Аю баласы: Нинди матур өй. Әни, анда нәрә бар?
Аю әни: Анда китап бар.
Аю баласы: Китап?
Аю әни: Әйе, китап. Матур китап.
Аю баласы (шыңшып): Китап кирәк, миңа китап кирәк.
Аю әни: Әйдә, - дип, аю баласын китап өенә алып керә.
Анда зур киштәләрдә матур-матур китаплар. Өстәлләр артында җәнлекләр китап укыйлар. Аю баласы шаккатып карап тора, әле бүре янына, әле төлке янына барып китапларна карый. Әнисеннән сорый:
- Әни, төлке нишли?
Аю әни: Төлке китап укый.
Аю баласы: Ә бүре нишли?
Аю әни: Бүре китап укый.
Аю баласы: Керпе нишли?
Аю әни: Керпе китап укый.
Аю баласы: Мин дә китап укыйм.
Аю баласы әнисе белән өстәл артында басып торган куян (китапханәче) янына килеп:

- Исәнме куян.
- Исәнме аю, нәрсә кирәк?
- Китап кирәк.
- Нинди китап?
- Зур (матур, зәңгәр) китап.
- Мә китап.
- Рәхмәт.

Куян китапны ала да, аю баласына бирә:
- Мә китап, укы – ди.

Аюлар өстәл артына барып утыралар, аю баласы китапны карый, бармагы белән йөртеп укый. Янәшә өстәлдә утырган бүре баласын күрә, ул рәсем ясый.

Аю баласы: Бүре, сн нишлисең?

Бүре: Мин рәсем ясыйм. Ә син нишлисең?

Аю баласы: Мин китап укыйм.

Алар янына төлке килә:
- Мин алма ясыйм (алма ясый, күрсәтә). Алма кызыл, тәмле.

Аю баласы: Мин туп ясыйм. Туп матур, туп сикерә (туп ясый).

Бүре: Мин шар ясыйм. Шар зур, яшел (шар ясый, яшелгә буйый).

Шатланалар, көлешәләр, бер берсенә рәсемнәрен күрсәтә-күрстә юлга чыгалар, аю әни артларыннан озата бара, һәрберсе үз юлы белән китә, саубуллашалар. Аю баласы әнисен җитәкләшеп сөйләнә-сөйләнә урманга кереп китәләр.

**16. Мультфильм (48 нче шөгыль) "Уйный-уйный укыйбыз"**

**Персонажлар:** Аю, бүре, төлке, куян, керпе, тычкан.

**Лексика:** Укыйм. Кем укый?

**Күренеш:** Урман. Урман аланында җәнлекләр мәктәбе. Ярым түгәрәк булып агач төпләре урнаштырылган – (*бу җәнлекләр өчен урындыклар)*. Биегрәк, зуррак агач төпләре - өстәлләр. Алда укытучы өстәле. Өстәлдә матур китаплар. Керпе укытучы. Калган җәнлекләр укучы ролендә парталар артында утыралар.

**Эчтәлек:** Керпе бер китапны алып күрсәтә. Бу нәрсә?

**Аю:** Бу китап.

**Керпе:** Китап нинди?

**Аю:** Китап зур, матур, кызыл, чиста.

**Керпе:** Кем укый?

**Куян:** Мин, мин укыйм, - дип кулын суза.

**Бүре:** Юк, юк! Мин укыйм. Китап зур, мин дә зур. Куян, син кечкенә.

**Керпе:** Туктагыз, спорлашмагыз! Аю, кил. Мә, зур китап, укы!

*Аю килеп китапны ала, урынына барып утыра "Теремкәй" әкиятен укый.*

Терем – терем – теремкәй,
Зур түгел ул, кечкенә.
Теремкәйдә кем яши?

**Тычкан:** Мин, тычкан. Пи – пи – пи!

**Куян:** Мин, куян (сызгырып җибәрә)
**Керпе:** (ачуланып) Куян, ярамый! Матур утыр!
**Бүре:** Мин, бүре.
**Төлке:** Мин, төлке.
**Керпе:** (аптырап тора да) Мин, керпе, - ди.
**Аю:** (соңыннан) Мин, аю. Зур аю.
*Җәнлекләр шатланалар, куанышалар, көлешәләр. Керпе кечкенә китапны ала, җәнлекләргә күрсәтә.*
**Керпе:** Бу нәрсә?
**Куян:** Бу китап.
**Керпе:** Китап нинди?
**Куян:** Китап кечкенә, матур, чиста, яшел.
**Керпе:** Кем укый?
**Куян:** Мин, мин укыйм. (кул күтәрә)
**Керпе:** Мә, куян, кечкенә китап, укы! Куян китапны ала, туп турында шигырь укый:
Туп, туп, матур туп.
Сикер, сикер, матур туп.
Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Сикер, сикер, матур туп.
*Җәнлекләр парта астыннан тупларын алалар, кырыйга чыгалар, шул ук шигырьне кабатлап тупны сикертә - сикертә уйныйлар.*
**Керпе башта шаккатып карап тора, соңыннан үзе дә тубын алып:**
Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Сикер, сикер, матур туп, - дип сикерә.
*Укучы җәнлекләр көлешеп карап торалар.Кыңгырау шалтырый, дәрес бетә. Җәнлекләр бер-берсе белән саубуллашып чыгып китәләр. Аланга барып туплары белән уйныйлар.*

**17. Мультфильм (51 нче шөгыль). “Урман мәктәбендә.”**
**Персонажлар:** Аю, бүре, төлке, куян, керпе, тычкан,
**Лексика:** Дәфтәр, китап, сана, рәсем ясыйм.
**Күренеш:** Урман. Урман аланында җәнлекләр мәктәбе. Ярым түгәрәк булып агач төпләре урнаштырылган –(*бу җәнлекләр өчен урындыклар)*. Биегрәк, зуррак агач төпләре - өстәлләр. Алда укытучы өстәле. Өстәл өстендә кыңгырау. Санау өчен кишерләр. Читтәрәк такта( яисә ковролин, магнитлы такта)
Укытучы ролен керпе башкара. Маңгаенда күзлек, кулында указка. Калган җәнлекләр укучы ролендә. Аларның Һәрберсендә картон портфельләр.
**Эчтәлек:**
**Керпе:** Исәнмесез!
**Җәнлекләр:** Исәнмесез.
**Керпе:** Хәерле көн! Утырыгыз! Әйдәгез танышабыз.
- Мин керпе. Мин укытучы. Син кем? (куяннан сорый)
**Куян:** Мин куян. Зур куян. Ак куян. Миңа 7 яшь. Мин сикерәм(сикерә)

**Керпе:** Матур куян. Утыр. Син кем? (тычканнанан сорый)
**Тычкан**: Мин тычкан. Кечкенә тычкан. Миңа 7 яшь. Мин җырлыйм (җырлый)
**Керпе:** Утыр, нәни дустым. (Бүрегә мөрәҗәгат итә) Син кем?
**Бүре:** Мин бүре. Зур, акыллы бүре. Миңа 7 яшь. Мин йөгерәбеләм. (йөгереп күрсәтә)
**Керпе:** Яхшы. Утыр бүре. (Төлкегә карап): Син кем?
**Төлке:** Мин төлке. Матур төлке, әйбәт төлке. Миңа 7 яшь. Мин биергә яратам (биеп күрсәтә)
**Керпе:** Бик яхшы, төлкекәй. Төлке матур бии?
**Бергә:** Төлке матур бии.
**Керпе:** (аюга) Ә син кем?
**Аю:** Ә мин зур аю. Көчле аю. Штанга күтәреп күрсәтә, саный. Миңа 7 яшь.
**Керпе:** Молодец аю. Син көчле. Утыр!
**Керпе:** Рәхмәт Матур итеп утырыгыз. Дәресне башлыйбыз.
**Керпе:** Куян, портфель бармы?
**Куян**: Әйе, бар (портфельне күрсәтә). Минем карандаш бар.
**Керпе:** Төлке, портфель бармы?
**Төлке:** Әйе, бар (портфельне күрсәтә). Минем китап бар.
**Керпе:** Тычкан, портфель бармы?
**Тычкан:** Әйе, бар (портфельне күрсәтә). Минем дәфтәр бар.
**Керпе:** Бүре, портфель бармы?
**Бүре**: Әйе, бар (портфельне күрсәтә). Минем альбом бар.
**Керпе:** Аю, портфель бармы?
**Аю:** Әйе, бар (портфельне күрсәтә). Минем карандаш бар. Мин саныйм.
**Керпе:** Бик яхшы. Хәзер бергә саныйбыз.
Санау дәресе.
*Керпе өстәлдә кәрзиннән кишерләр алып куя, унга кадәр бергә саныйлар.*
**Бергә:** Бер кишер, ике кишер, ..., ун кишер.
**Керпе:** Куян, кил монда. Сана. (куян кишерләргә карап тора, берсен алып ашый башлый)
**Куян:** (саный) Бер кишер, ике кишер,...сигез кишер, *(тагын кишерне кабып куя)*
Керпе (күзлек астыннан көлемсерәп карап тора): Куян, нишлисең?
**Куян** (горур гына): Кишер ашыйм. Мин кишер яратам. Кишер тәмле.
**Керпе:** Сана! Ничә кишер?
**Куян** ( бер кишерне артына яшереп тора, саный): Бер кишер, ике кишер,...сигез кишер, тугыз кишер.
**Керпе:** Ничә кишер?
**Куян:** Тугыз кишер.
**Аю**(кул күтәрә): У – у – у! Юууук! Юуууууууук!
**Керпе:** Аю, кил монда. Сана.
Аю килә, кишерләрне саный, куянның артына яшергән кишерен ала да өстәлгә куя.
**Аю:** Ун кишер. (куянга борылып, кисәтү ясый): Ярамый. Ярамый.

**Керпе:** Әйдәгез тагын сакыйбыз (саныйлар)
**Бергә:** Бер кишер, ике кишер,...сигез кишер, тугыз кишер, ун кишер.
<u>Рәсем дәресе.</u>
**Керпе:** Бик яхшы. Хәзер рәсем ясыйбыз. Һәрберсенә эш бирә.
**Керпе:**
- Куян ике кишер ясый.
- Төлке биш шар ясый.
- Тычкан бер туп ясый.
- Бүре китап ясый.
- Аю алма ясый.

*Керпе һәрберсен карап йөри, мактый.Җәнлекләр нәрсә ясаганнарын әйтәләр.*
**Куян:** Мин кишер ясыйм.
**Тычкан:** Мин шар ясыйм.
**Төлке:** Мин туп ясыйм.
**Бүре:** Мин китап ясыйм.
**Аю:** Мин алма ясыйм.
*Керпе бүренең китабын ала.*
**Керпе**: Матур китап!
*(Үзенең китабын алып балаларга күрсәтә):*
- Минем матур, кызыклы китап бар. Мин китап укыйм. Тыңлагыз!

*(китап укый, җәнлекләргә бирә)*
- Кишер матур, кишер тәмле. Куян, мә кишер.
- Шар матур, зур шар. Тычкан, мә шар.
- Туп матур. Кызыл туп. Төлке, мә туп.
- Китап матур. Китап чиста. Бүре, мә китап.
- Алма кызыл. Алма баллы. Аю, мә алма.

**Керпе** (кыңгырау чыңлата(шалтырата): Дәрес бетте. Тәнәфескә чыгабыз. Уйныйбыз, биибез, җырлыйбыз.

**18. Мультфильм (54 нче шөгыль) “Теремкәй.”**
**<u>Персонажлар:</u>** тычкан, куян, керпе, бүре, төлке, аю.
**<u>Күрнеш:</u>** Урман, урманда теремкәй тора.
**<u>Эчтәлек:</u>**
**Тычкан килә:** Мин тычкан, кечкенә тычкан, матур тычкан. Мин ипи, сыр яратам. Ай-яй-яй нинди матур өй. Ишек шакый, сорый:
Терем, терем, теремкәй,
Зур түгел, ул бәләкәй.
Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан теремкәйне карый:** Беркем дә юк. Мин яшим (теремкәйгә керә).
Ишек шакыган тавыш.
**Балалар:** Кем анда?
**Куян:** Мин куян.
**Балалар:** Куян, кил монда.

**Куян:** Мин куян. Ак куян, матур куян. Кишер, кәбестә яратам. Ай-яй-яй, нинди матур өй!
**Куян балалар белән сорый:**
Терем, терем, теремкәй,
Зур түгел, ул бәләкәй.
Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан. Ә син кем?
**Куян:** Мин куян.
**Тычкан:** Куян, кил монда. Кер.
**Куян:** Рәхмәт.
Ишек шакыган тавыш.
**Балалар:** Кем анда?
**Керпе:** Мин керпе. Кечкенә керпе. Матур керпе. Мин сөт, алма яратам. Ай-яй-яй, нинди матур өй!
**Керпе балалар белән сорый:**
Терем, терем, теремкәй,
Зур түгел, ул бәләкәй.
Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан.
**Куян:** Мин куян. Син кем?
**Керпе:** Мин керпе.
**Тычкан, куян:** Керпе, кил монда. Кер.
**Керпе:** Рәхмәт.
Ишек шакыган тавыш.
**Балалар:** Кем анда?
**Төлке:** Мин төлке. Матур төлке, зур төлке. Мин биим, биергә яратам. Әйдәгез биибез. ***(Бию).***
**Тычкан:** Мин тычкан.
**Керпе:** Мин куян.
**Төлке балалар белән сорый:**
Терем, терем, теремкәй,
Зур түгел, ул бәләкәй.
Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан.
**Куян:** Мин куян.
**Керпе:** Мин керпе. Ә син кем?
**Төлке:** Мин төлке.
**Тычкан, керпе, куян:** Төлке, кил монда. Кер.
**Төлке:** Рәхмәт.
Ишек шакыган тавыш.
**Балалар:** Кем анда?
**Бүре:** Мин бүре. Мин матур бүре, зур бүре. У-у-у, җырлыйм. Әйдәгез җырлыйбыз. ***(Җыр).***
**Бүре балалар белән сорый:**
Терем, терем, теремкәй,

Зур түгел, ул бәләкәй.
Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан.
**Куян:** Мин куян.
**Керпе:** Мин керпе.
**Төлке:** Мин төлке. Син кем?
**Бүре:** Мин бүре.
**Тычкан, керпе, куян, төлке:** Бүре, кил монда. Кер.
**Бүре:** Рәхмәт.
Ишек шакыган тавыш.
**Балалар:** Кем анда?
**Аю:** Мин аю. Мин матур аю, зур аю. Ай-яй-яй, нинди матур өй.
**Аю балалар белән сорый:**
Терем, терем, теремкәй,
Зур түгел, ул бәләкәй.
Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан:** Мин тычкан.
**Куян:** Мин куян.
**Керпе:** Мин керпе.
**Төлке:** Мин төлке.
**Бүре:** Мин бүре. Син кем?
**Тычкан, керпе, куян, төлке, бүре:** Аю, кил монда. Кер.
**Аю:** Рәхмәт. Мин йоклыйм.

**19. Мульфильм (57 нче шөгыль) “Кем нәрсә ярата?”**

**Персонажлар:** Эт, песи, әтәч, кәҗә.
**Күренеш:** Өй макеты. Бу өйдә әтәч, эт, песи, кәҗә яшиләр.
Ишегалдында яшел чирәм үсә. Өйдән ерек түгел эт оясы. Иртә. Кошлар сайраган тавышлар ишетелә. Киртәгә әтәч сикереп менә. Канат кагып кычкыра.
Әтәч: Кикри-күк, кикри-күк.
Әтәч киртәдән сикереп төшә дә, чирәм чүпли башлый. Ко-ко-ко.
Өйдән әкрен генә, ялкау атлап, песи чыга, киерелә: мияу-мияу-мияу.

**Эчтәлек:**

**Песи әтәчкә карап:** Хәерле көн, әтәч!
**Әтәч:** Хәерле көн, песи!
**Песи:** Хәлләр ничек, әтәч?
**Әтәч:** Әйбәт. Рәхмәт. Ә синең хәлләрең ничек?
Шул вакыт йөгерә-йөгерә эт чабып чыга.
**Эт:** Һау-һау-һау. Исәнме, әтәч! Исәнме, песи!
**Әтәч белән песи:** Исәнме, эт.
**Эт:** Кәҗә кая?
**Әтәч белән песи:** Әнә, кәҗә кәбестә ашый. Ул кәбестә ярата.
**Эт:** Ә мин, ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?
**Песи:** Мин сөт яратам. Сөт тәмле. Әтәч, син нәрсә яратасың?
**Әтәч:** Мин ботка яратам. Ботка тәмле.
Кәҗә килә, кәрзинендә кәбестә, сөт, ипи, ботка.

**Кәҗә:** Исәнмесез. Хәерле көн. Хәлләр ничек?
**Бергә:** Әйбәт.
**Кәҗә:** Мин кәбестә ашадым. Кәбестә бик тәмле. Акбай, мә кәбестә, аша. Кәбестә тәмле!
**Акбай:** Юк, мин ипи яратам. Син кәбестә аша. Миңа ипи кирәк.
**Кәҗә:** Мә, ипи, аша.
**Акбай:** Рәхмәт. Ипи тәмле.
**Песи:** Мин сөт яратам. Ә сөт юк.
**Кәҗә:** Сөт бар. Кил монда Песи, кил монда, сөт ал, эч.
**Песи (сөт эчә):** Мин сөт эчәм. Сөт тәмле. Әтәч, кил монда, сөт эч.
**Әтәч:** Юк, мин сөт яратмыйм. Мин ботка яратам. Ә ботка юк.
**Кәҗә:** Ботка бар, кәрзиндә. Әтәч, мә, ботка аша.
**Әтәч:** Зур рәхмәт, кәҗә. Ботка бик тәмле. Мә кәҗә, ботка аша.
**Кәҗә:** Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.
**Әтәч:** Юк, ботка тәмле.
**Песи:** Юк, сөт тәмле.
**Эт:** Юк, ипи тәмле.
Ишектән кыз чыга. Кыз аларның бәхәсләшкәннәрен тыңлап тора да, алар янына килә.
**Кыз:** Ипи дә тәмле, сөт тә тәмле, ботка да тәмле, кәбестә дә тәмле. Мин барысын да яратам.
Бергә җырлап, бииләр.
*Ипи тәмле, сөт тәмле,*
*Ботка, кәбестә тәмле.*
*Әйе шул, әйе шул,*
*Ипи тәмле, сөт тәмле,*
*Әйе шул, әйе шул,*
*Ботка, кәбестә тәмле.*

## МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ (АРАЛАША) БЕЛҮ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ТИКШЕРҮ.

### Тикшерү үткәрү буенча киңәшләр.

Балаларның татар телендә аңлау һәм сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен уку елы башында (октябрь ае) һәм уку елы ахырында (апрель аенда) тикшерелә. Уртанчылар төркеме балалары белән тикшерү уку елы ахырында үткәрелә. Уку елы уртасында тематик тикшерү (декабрь, январь) үткәререгә мөмкин.

Тикшерүне һәр бала белән аерым, 1 – 2 бала катнашында, ә йомгаклау эшчәнлеге булганда барлык балалар белән бергә дә үткәрергә була. Тикшерү вакыты 10-15 минутан артмаска тиеш.

Биремнәр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып үткәрелә, уенбирем рус телендә аңлатыла. Биремнәр мавыктыргыч һәм кызыклы булырга тиеш. Сораулар ачык, төгәл итеп, интонация белән

бирелә.Тикшерүче балаларның җавабын тыңлаганда елмаеп, кирәк булса җавапны дөресләп, бала әйтә алмаганда булышырга тиеш.

Тикшерү барышында яңа материал бирелми. Тикшерүне эш дәфтәрләре, таратма, күрсәтмә рәсемнәр, интерактив тактада уеннар кулланып үткәрергә дә була.

Биремнәр, уеннар өчен кирәк булган күрсәтмәлелек алдан әзерләнеп куелган булырга тиеш. Тикшерүче һәр биремгә аерым балл куеп бара. Тикшерү ахырында баллар саны кушыла һәм 5 кә бүленә. Шулай итеп гомуми нәтиҗә ясала.

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының**

**“Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| | Баланың исеме, фамилиясе | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | баллар | дәрәҗә |
| | | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч) | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

| Нәтиҗәләрне билгеләү | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.**

1. “**Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**

1. ***Дидактик уен. "Бу кем?"*** *(I вариант)*

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)

Уен эчтәлеге: Өй рәсеме. Өй тирәсендә гаилә әгъзалары рәсемнәре (комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр). Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: Бу кем? ("Әни"...).

2. ***Дидиктик уен "Кем юк?"*** *(II вариант)*

(Лексика шул ук).Уен шул ук рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче бер рәсемне алып куя. Баладан сорый: "Кем юк?" ("Әби"...)

Уенны интерактив тактада да, бала белән бала арасында диалог формасында да үткәрергә була)

3. ***Дидактик уен "Кәрзиндә нәрсә бар?"***

(Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)

Уен эчтәлеге: Мияу кәрзин белән ашамлыклар алып килгән. Мияу ашамлык муляжларына күрсәтә, исемен сорый: "Бу нәрсә?" ("Алма"...)

4. ***Дидактик уен "Нәрсә юк?"***

Мияу бер ашамлык муляжын яшереп куя: "Нәрсә юк?". Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. ("Алма"...) Уенны рәсемнәр кулланып та үткәреп була.

***5. Дидактик уен "Мин әйтәм, син күрсәт һәм әйт"***

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай; куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).

Уен эчтәлеге: Балага уенчык яисә уенчык рәсемнәре бирелә. Бала, тәрбияче әйткән уенчыкны яисә уенчык рәсемен табып күсәтергә һәм исемен кабатлап әйтергә тиеш.

***6. Дидактик уен "Исемен әйтсәң бирәм"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Тәрбияче өстәлендә уенчыклар яисә рәсемнәр. Тәрбияче балага уенчыкны(рәсемне) күрсәтә, сорый: "Бу нәрсә?"- "Алма"... ; "Бу кем?"-"Әти"... Бала уенчык исемен дөрес әйтсә аңа уенчыклар, яисә таратма рәсемнәр бирелә.

***7. Дидактик уен "Серле янчык"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Балага уенчыклар күрсәтелә, исемнәрен әйтеп янчыкка салына. Бала янчыктагы уенчыкны капшап исемен әйтә, алып күрсәтә.

***8. Дидактик уен "Әйе-юк"***

Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү йөзеннән (аңлап яки аңламыйча әйтү) төрле вариантта сораулар бирелә: "Бу нәрсә?" - "Аю"...; "Бу аю?" - "Әйе, аю"...; "Бу куян?" - "Юк, песи"...

**Югары балл (2.7-3)** — сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә.

**Уртача балл (2-2,6)** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

**2. Ягымлы сүзләр куллану ("исәнме", "сау бул", "рәхмәт").**

***Ситуатив күнегүләр:***

а) Ситуатив күнегү "Куян аюга кунакка килә". Ул ишектән кергәндә аюга нәрсә әйтә? (Ничек исәнләшә?), "Исәнме аю".

б) Ситуатив күнегү “Куян аюда кунакта булды”. Ишектән чыгып киткәндә куян аю белән ничек саубуллаша? (Нәрсә әйтә?) "Сау бул, аю".

в) Уен ситуациясе "Кунак сыйлау". Акбайда (Мияуда) кунакта.

Тәрбияче Акбай (Мияу) ролендә. Ул баланы, ашамлык, җиләк-җимеш (алма, груша, банан һ.б.) муляжлары белән "сыйлый". Тәрбияче баланың "рәхмәт" әйтә белүен билгели.

г) Уен ситуациясе "Дустыңны сыйла". Балаларны парлаштырып бер-берсен сыйларга тәкъдим итү. Рәхмәт әйтә белүләрен билгеләү.

д) Ситуатив күнегү "Акбайга ("Мияуга", "Курчакка", "Дустына") уенчык бүләк ит".

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** - бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** - тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** - аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.

**3. Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч).**

**1. Сүзле уен "Мин әйтәм - син эшлә" ("Командир").**

**2. Сүзле уен "Шаян уенчыклар"** (Уен баланың боерыкларны аңлы рәвештә үтәвен тикшерү өчен бирелә. Уенның эчтәлеге: Тәрбияче уенчыкка боерык бирә, мәсәлән: Утыр! Ә уенчык “ашый” башлый. Бала боерыкны дөрес итеп үтәп күрсәтә).

**<u>Югары дәрәҗә (2,7-3)</u>** - бала боерыкны аңлап, дөрес үти.

**Уртача дәрәҗә (2-2,6)** - ялгыша.

**<u>Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)</u>** - татарча аңламый, боерыкларны үтәми.

**4.Тирә-юньдәге предметларның сыйфат билгеләрен, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану.**

***<u>1. Дидактик уен "Уенчык нинди?" (зур, кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур).</u>***

Уен эчтәлеге: зур-кечкенә уенчыклар күрсәтелә. Тәрбияченең "Нинди?" соравына бала уенчыкның исемен сыйфат билгесе белән әйтергә тиеш.

-Нинди курчак? - Зур (кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур) курчак.

Эш дәфтәрендәге 11 нче биремне кулланып була.

*2. Дидактик уен "Тап, күрсәт һәм әйт" (чиста, пычрак).*
Комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче әйткән рәсемне бала табып күрсәтә, әйтә.("Чиста туп", "Пычрак аю"...).

Эш дәфтәрендәге 13 нче биремне кулланып була.

***3. Дидактик уен "Курчакка бүләк".***
Тәрбияче зур курчакка- зур туп, кечкенә курчакка- кечкенә туп бүләк итәргә куша. “ Мә, зур туп ", “Мә, кечкенә туп".

***4. Дидактик уен "Дөрес сана".***
Санау күнекмәләрен билгеләү (1-5 кадәр). Тәрбияче уенчыклар, муляжлар санарга тәкъдим итә. Төркемдәге балаларны да санарга була. "Ничә малай?", "Ничә кыз?".

***5. Дидактик уен "Ничә?".***
Санау күнекмәләрен тикшерү өчен шулай ук, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне дә кулланып була.

- Ничә туп? - Биш туп.

**Югары дәрәҗә (2,7-3)** - әйберләрнең сыйфат билгеләрен, күләмен исем белән кушып дөрес әйтә.

**Уртача дәрәҗә (2-2.6)** - 1-2 билгесен әйтә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)** - әйберләрнең билгеләрен, күләмен рус телендә әйтә.

### 5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау).

***1. Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".***

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә. К нам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться: -Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля (Коля). -Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай (әйе, мин кыз).

***2. Уен ситуациясе "Кунак каршылыйбыз ".***

а) Тәрбияче: К нам идут гости.

***Спроси. "Кто там?". "Кем анда?"*** - Мин әби (бабай).

***"Позови бабушку (дедушку)".*** - Әби (бабай) кил монда.

***"Поздоровайся с бабушкой (дедушкой)"*** - Исәнме, әби (бабай).

***"Спроси у бабушки (дедушки) как дела?"*** - Әби (бабай) хәлләр ничек? - Әйбәт, рәхмәт.

***"Предложи бабушке (дедушке) сесть".*** - Әби (бабай) утыр.

***"Предложи бабушке (дедушке) пить чай"*** - Мә, чәй, эч.

***Скажи: "До свидания!"*** Сау бул, әби! (бабай).

б) Балага "кунак" белән исәнләшергә, хәлен сорарга, чакырып утыртырга, сыйларга ("аша,эч") һәм саубуллашырга тәкъдим итеЛә.

Эш дәфтәрендәге 3 нче биремне кулланып була.

***1. Уен ситуациясе "Кунакларны сыйла".***
***Угости Акбай хлебом, Мияу молоком.***

-Мә, Акбай ипи, аша. - Рәхмәт.

-Мә, Мияу сөт, эч. - Рәхмәт.

Эш дәфтәрендәге 16 нчы биремне кулланып була.

***2. Уен ситуациясе "Бер - береңне сыйла ".***

*(Ашамлык муляжлары кулланып)*

***"Угости яблоком".***

- Мә, алма, аша. - Рәхмәт.

***"Спроси, яблоко вкусное?"***

- Алма тәмле? - Әйе, тәмле.

Эш дәфтәрендәге 6 нчы биремне кулланып була.

***3. Уен ситуациясе "Уенчыклар илендә"***

***1 . Ты пришел в магазин игрушек. Попроси игрушку, которая тебе нравится.***

-Куян бир (әле).- Рәхмәт.

***2. Предложи поиграть с игрушкой.***

- Мә, туп, уйна. - Рәхмәт.

***3. Позови друга, предложи помыть игрушку.***

-Коля, кил монда. -  Мә, туп, ю.

***4. Поменяйтесь игрушками. Попроси у друга игрушку, предложи ему свою .***

- Коля, туп бир  - Мә, туп.

- Рәхмәт.

**Югары дәрәҗә (2,7-3)** - аралаша, сөйләм күнекмәләрен актив куллана.

**Уртача дәрәҗә (2-2,6)** - тәрбияче ярдәмендә аралаша.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

### Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

| | | **Биремнәр** | | | | | **Нәтиҗә** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |
| | Баланың исеме, фамилиясе | “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”. “исәнмесез”, “ сау булыгыз”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**1.“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**
**(Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

***1. <u>Дидактик уен “Бу нәрсә?”</u>***
(Лексика: аш, ботка, сөт, кашык, тәлинкә, чынаяк).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:
- Бу нәрсә? (“Аш”...)

***2. <u>Дидактик уен “Кәрзиндә нәрсә бар?”</u>***
(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Уен эчтәлеге: Куян кәрзин белән яшелчәләр һәм җиләк-җимеш алып килгән. Куян сорый: “Нәрсә бар?” (“Кәбестә”...)

3. ***<u>Дидактик уен “Нәрсә юк?”.</u>***
(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Куян бер яшелчә муляжын яшереп куя: “Нәрсә юк?”. Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

***4. <u>Дидактик уен “Дөресен әйт”.</u>***
(Лексика: күлмәк, чалбар, сарафан, өстәл, урындык, карават).
Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрнең исемен атый һәм күрсәтә.

**<u>Югары балл (2.7-3)</u>** — сүз байлыгы җитәрлек, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары атамаларын аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә һәм куелган сорауларга җавап бирә.

**Уртача балл (2-2,6)** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

**2. Ягымлы сүзләр куллану (“Исәнме”, “Сау бул”, “Рәхмәт”, “Исәнмесез”, “ Сау булыгыз”).**

***Ситуатив күнегүләр (уртанчылар төркемендәге ягымлы сүзләр бүлеген кара):***

а) Поздоровайся с Акбаем.

б) Спроси как дела у Акбая.

в) Скажи спасибо Акбаю. Спроси как дела.

г) Попрощайся с Акбаем.

д) Поздоровайся с воспитателем, Мияу и Акбай.

е) Попрощайся с воспитателем, Мияу и Акбай.

**Югары балл (2.7-3)** — бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

**Уртача балл (2-2,6)** – уен ситуацияләрен тәрбияче ярдәмендә төзи.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** – аңлый, җавап бирә алмый.

**3. Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал).**

Балаларның боерыкларны бирә белү күнекмәләрен тикшерү. Балалар бер-берсенә боерык бирәләр. Саша, аша! – Саша ашау хәрәкәтләре күрсәтә. Алга таба Саша үзе башка балага боерык бирә һәм шундый тәртиптә дәвам ителәә.

(Лексика: кил, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал).

**Югары балл (2,7-3)** – 8-9 сүз.

**Уртача балл (2-2.6)** – 5-6 сүз.

**Уртачадан түбән (1-2)** – 1-2 сүз.

**4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).**

***1. Сюжетлы-рольле уен “Кибет”***

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куя белүләрен максат итеп куясың. Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары рәсемнәре кулланып үткәрелә.

(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

*2.* ***Дидактик уен "Нинди?".***

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.

Әйберләрне билгесен ачыклау өчен бирелә торган сорауга аңлап җавап бирү һәм ул сорауларны үзлектән куя белү.

(Лексика: нинди? кызыл, сары, яшел, зәңгәр).

**3.** ***Дидактик уен "Ничә?".***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

*4.* ***Дидактик уен "Дөрес сана".***

Тәрбияче уенчыклар, муляжлар, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне санарга тәкъдим итә. Балалар бер-берсенә сорау бирәләр һәм җавап бирәләр. Шулай ук, сорауны тәрбияче үзе дә бирә ала. *"Ничә...?".*

**Югары балл (2,7-3)** – диалогта 3 сорауны да аңлап куллана**.**

**Уртача балл (2-2.6)** – диалогта 2 сорауны аңлап куллана**.**

**Уртачадан түбән (1-2)** – диалогта 1 сорауны аңлап куллана**.**

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкаръ итү, раслау).**

***1. Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".***

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә.

К вам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться:

- Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля яки Коля).
- Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай).

***2. Уен ситуациясе "Кунак каршылыйбыз".***

а)Тәрбияче:

- К нам идут гости. Спроси. "Кто там?". "Кем анда?"
- Мин Акбай.
- Позови Акбая.
- Акбай, кил монда.

б)У Акбая сегодня день рождение. Подари свою игрушку
- Акбай, мә кызыл туп.
- Рәхмәт.

в) Угости гостей супом или кашей.
- Мә, аш (ботка) (аша).

г)Что бы сьесть угощение попроси ложку.
- Кашык бир.
- Нинди кашык?
- Зур, матур, зәңгәр кашык.
- Рәхмәт.

***3. <u>Уен ситуациясе “Кибеттә”.</u>***

Бала белән бала аралашуы тикшерелә.
- Исәнме! Хәлләр ничек?
- Әйбәт, рәхмәт.
- Аю бир.
- Нинди аю?
- Зур аю, чиста аю, матур аю.
- Ничә?
- Ике аю.
- Мә, ике аю.
- Рәхмәт.
- Сау бул.

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.

**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.

**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – аңлый, русча җавап бирә.

**Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| | Баланың исеме, фамилиясе | **Биремнәр** | | | | | **Нәтиҗә** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме” “исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”, “зур рәхмәт”, | Боерыкны бирә белү(кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, жырла, | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**1.“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**
**(Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

1. ***Дидактик уен “Бу нәрсә?”***

(Лексика: тычкан, бүре, төлке, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, аю).

Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:

- Бу нәрсә? (“бүре”...)

2. ***Дидактик уен “Портфельдә нәрсә бар?”***

(Лексика: китап, дәфтәр, рәсем, мәктәп).

Уен эчтәлеге: Тәрбияче портфельдән рәсемнәр яки предмет алып күрсәтә, исемен сорый:

-Портфельдә нәрсә бар?- (“Дәфтәр бар”...)

3. ***Дидактик уен “Портфельдә нәрсә юк?”***

Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

4. ***Дидактик уен “Дөресен әйт”***

(Лексика: чәк- чәк, өчпочмак, бәрәңге, аш, ботка, су).

Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрне атый.

**Югары балл (2.7-3)** — 10-14 сүз.

**Уртача балл (2-2,6)** – 7-9 сүз.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** – 1-6 сүз.

## 2. Ягымлы сүзләр куллану

## (“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”, “Зур рәхмәт”, “Хәерле көн”,“Хәлләр ничек?”, “Әйбәт”)

***Ситуатив күнегү:***

Телефоннан сөйләшү.

Эш дәфтәрендәге 1 нче биремне кулланып була.

**Югары балл (2,7-3)** — бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

**Уртача балл (2-2,6)** – тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** – аңлый, сорауларга җавапны русча бирә.

## 3. Боерыкны бирә белү.

(Лексика: кил монда, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал, йөгер, бие, җырла, йокла).

***Дидактик уен: “Командир”***

Эш дәфтәрендәге 9 нчы биремне кулланып була**.**

Бер бала икенче балага боерык бирә. Мәсәлән:

-Коля, сикер! (Коля сикереп күрсәтә).

-Коля, син нишлисең?(Колядан сорый) – Мин сикерәм.

-Коля нишли? (Башка баладан сорый) – Коля сикерә.

**Югары балл (2,7-3)** — 11-13 сүз белән боерык бирә, син нишлисең, нишли сорауларын бирә белә.

**Уртача балл (2-2,6)** – бары боерык бирә, сорауларны куя алмый.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** – 1-5 сүз белән боерык бирә, сорауларны русча әйтә.

## 4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?)

***1. Уен ситуацияләре:***

а) “Кибет” (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?)

б) “Телефоннан сөйләшү” (Кая барасың? Син нишлисең?)

в) “Танышу” (Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли?)

***2. Сюжетлы-рольле уен “Кибет”***

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куллана белүләре тикшерелә.Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары, йорт кошлары, уенчык рәсемнәре кулланып үткәрелә.

(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

***2. Дидактик уен “Нинди?”.***

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.

(Лексика: кызыл, сары, яшел, зәңгәр, ак, кара).

**3.** ***Дидактик уен “Сана”.***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

**Югары балл (2,7-3)** – сорауларны аңлап куллана**.**

**Уртача балл (2-2,6)** – аңлый, тәрбияче ярдәме белән куллана**.**

**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – русча җавап бирә.

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау)**

***1. <u>Уен ситуациясе “Әйдәгез танышабыз”</u>***

- Исәнмесез. Син кем? - (Мин Оля яки Коля).
- Мин кыз. Син кыз? - (Юк, мин малай).
- Сиңа ничә яшь?- (6 (7) яшь).

***2. <u>Уен ситуациясе “Телефоннан сөйләшү”.(диалогны сан, сыйфат, күләм берәмлеге кертеп баетырга була)</u>***

- Исәнме. Хәлләр ничек?
- Әйбәт.
- Нишлисең?
- Мин уйныйм. Син нишлисең?
- Мин ашыйм.
- Нәрсә?
- Алма ашыйм.
- Алма тәмле(ме)?
- Әйе, алма тәмле.
- Сау бул.

3. ***<u>Уен ситуациясе “Кая барасың?”</u>*** (*мәктәп, кафе, цирк һ.б.*)

- Исәнме! Хәлләр ничек?
- Әйбәт, рәхмәт.
- Кая барасың?
- Кафега барам.
- Кафеда нәрсә бар?
- (ашамлыклар атарга мөмкин)
- Саша нишли?
- Саша бәрәңге ашый.

4.***<u>Ситуатив күнегү.</u>***

а) Син нишлисең?

- Мин биим (утырам, сикерәм, ашыйм, эчәм, уйныйм, йөгерәм, җырлыйм, йоклыйм).

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.

**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.

**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – аңлый, русча җавап бирә.

**Файдаланылган әдәбият:**

*Борһанова Р. А., Юсупов Ф. Ф.* Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы. – Казан, 2004.

*Алексеева Р. М.,Исаева Р. С.,Зарипова З. М.,Камалова А. И.,Кидрячева Р. Г.*

Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. - Казан, 2013.

*Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г. ,Камалова А. И.*Планирование деятельности по обучению дошкольников татарскому языку. Методическое пособие. – Казань:Татарское республиканское издатеьство “ХЭТЕР”, 2018.

*Шаехова Р.К.* Региональная программа дошкольного образования “Сөенеч – Радость познания”. 2016.